ДҮШӘМБЕ
1 АПРЕЛЬ
1940 ел
№ 75 (5875)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик һәм культура бүлекләре 18—22, авыл хуҗалыгы бүлеге 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, информация һәм совет төзелеше бүлекләре 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

СССР НЫҢ I НЧЕ ЧАКЫРЫЛЫШ ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫНЫҢ АЛТЫНЧЫ СЕССИЯСЕ

ХӨКҮМӘТНЕҢ ТЫШКЫ ПОЛИТИКАСЫ ТУРЫНДА

Халык Комиссарлары Советы Председателе һәм Чит Ил Эшләре Халык Комиссары иптәш **В. М. Молотовның** 1940 нчы елның 29 нчы мартында ССР Союзы Верховный Советы утырышында ясаган доклады

Депутат иптәшләр!

Верховный Советның соңгы Сессиясеннән бирле биш ай вакыт үтте. Бу кыска гына чор эчендә халыкара мөнәсәбәтләрнең үсешендә беренче дәрәҗәдә әһәмияте булган вакыйгалар булды. Шул уңай белән Верховный Советның бу Сессиясендә безнең тышкы политикабызга кагылышлы мәсьәләләрне карарга кирәк.

Халыкара тормыштагы соңгы вакыйгаләрне, барыннан да элек, үткән елның көзендә Үзәк Европада башланган сугыш күзлегеннән карарга кирәк. Англия-Франция блогы белән Германия арасындагы сугышта әлегә кадәр зур бәрелешләр булмады һәм эш башлыча диңгездә, шулай ук һавада булган аерым бәрелешләр белән чикләнде. Ләкин маглүм ки, Германиянең үткән елның ахрында ук инде күрсәткән тынычлыкка омтылышын Англия һәм Франция хөкүмәтләре кире кактылар, шунлыктан ике яктан да сугышны җәелдерүгә хәзерлек тагын да көчәйде.

Соңгы чорда 80 миллионга якын немецләрне берләштергән, кайбер күрше дәүләтләрне үз хакимлеге астына алган һәм сугыш ягыннан бик нык көчәйгән Германия, күренә ки, Европадагы төп империалистик державаларның—Англиянең һәм Франциянең куркынычлы конкуренты булып әверелде. Шуңа күрә дә алар үзләренең Польшага карата йөкләмәләрен үтәү сылтавы астында Германиягә каршы сугыш иглан иттеләр. Хәзер бу державалар хөкүмәтләренең чын максатлары таркалган Польшаны яки Чехо-Словакияне яклау интересларыннан никадәр ерак торганлыгы [illegible] күренә. Бу Англия һәм Франция хөкүмәтләренен Германияне бу сугышта тар-мар итүне һәм бүлгәләүне үзләренең максатлары дип иглан итүләреннән генә дә күренә, хәер бу максатларны халык массасыннан әле һаман да „демократик“ илләрне һәм кечкенә халыкларның „хокукларын“ яклау лозунглары белән яшереп киләләр.

Германиягә каршы бу империалистик политиканы үткәрүдә Советлар Союзы Англиягә һәм Франциягә булышчы булырга теләмәгәнлектән Советлар Союзына карата аларның дошманлык позицияләре тагын да көчәйде, социалистик дәүләткә каршы империалистларның дошманлык политикаларының сыйнфи тамырлары никадәр тирән икәнлекне ачык күрсәтте. Финляндиядә башланган сугышны исә Англия-Франция империалистлары СССР га каршы сугышу өчен чыгыш пункт итәргә һәм моның өчен Финляндиянең үзеннән генә түгел, бәлки Скандинавия илләреннән—Швециядән һәм Норвегиядән дә файдаланырга хәзер торганнар иде.

Европада җәелеп бара торган сугышка Советлар Союзының карашы маглүм. СССР ның тынычлык сөю белән сугарылган тышкы политикасы монда да тулы ачыклык белән күрсәтелде. Советлар Союзы башта ук үзенең нейтралитет позициясендә торуын белдерде һәм үткән бөтен чор буена бу политиканы туктаусыз үткәреп килде.

Советлар Союзы белән Германия арасындагы мөнәсәбәтләрдә яхшы якка таба текә борылыш, һөҗүм итешмәү турында үткән елның августында кул куелган договорда чагылды. Совет-Германия арасындагы бу яңа, яхшы мөнәсәбәтләр элекке Польшадагы вакыйгалар уңае белән тәҗрибәдә тикшерелделәр һәм үзләренең ныклыкларын җитәрлек күрсәттеләр. Шул вакытта ук, үткән елның көзендә үк экономик мөнәсәбәтләрне үстерүнең күздә тотылуы 1939 нчы елның августындагы, ә аннары 1940 нчы елның февралендәге сәүдә килешүләрендә дә конкрет төстә чагылды. Үзара хуҗалык уңайлыклары нигезендә Германия белән СССР арасында товар обороты арта башлады һәм аның тагын да үсүе өчен нигезләр бар.

Англия һәм Франция белән безнең мөнәсәбәтләребез бер кадәр башкачарак булдылар. Германиягә каршы бөтен дөньяда өстенлек өчен Англия-Франция империалистларының көрәшендә Советлар Союзы корал булырга теләмәгәнлектән, безгә атлаган саен аларның безнең илебезгә карата тирән дошманлык политикаларына очрарга туры килде. Финляндия мәсьәләсендә эш бигрәк тә еракка китте, бу турыда мин соңрак тукталырмын. Ләкин СССР га карата соңгы айларда Франция һәм Англия политикасының башка төрле дошманлык фактлары да аз булмады.

Франция властьларының моннан ике ай элек Парижда безнең сәүдә илчелегенә полиция һөҗүме ясаудан да яхшырак нәрсә тапмаганлыкларын гына әйтү дә җитә. Барлык бәйләнүләргә дә карамастан, сәүдә илчелегендә ясалган тентү бер нинди нәтиҗәләр бирмәде. Ул бары тик бу әшәке эшне башлап йөрүчеләрне хурлыкка гына калдырды һәм безнең илебезгә карата мондый дошманлык акты өчен бер нинди дә реаль сылтаулар булмаганлыкны күрсәтте. Франциядәге тулы хокуклы вәкилебез иптәш Сурицны чакырып алуга бәйләнешле эшнең детальләреннән күргәнебезчә, Франция хөкүмәте Советлар Союзына карата үзенең дусларча булмаган карашын күрсәтү өчен ясалма сылтаулар эзли. Һәр ике ил арасындагы мөнәсәбәтләр белән Советлар Союзының Франциягә караганда артык кызыксынмаганлыгы ачык булсын өчен без иптәш Сурицны Франциядә полпредлык хезмәтләреннән чакырып алдык.

Яки Америкадан һәм Кытайдан сатып алынган товарларны төяп Владивостокка килә торган ике пароходыбызны Ерак Көнчыгышта Англиянең сугыш карабларының басып алулары кебек, СССР га карата шундый дошманлык актларын алып карагыз. Шуның өстенә Англиядә безнең промышленность җиһазларына биргән элекке заказларыбызны үтәүдән баш тартулары, Франциядәге сәүдә илчелегенең акчаларына арест салыну һәм күп кенә башка шундый фактларны өстәсәк, Советлар Союзына карата Англия һәм Франция властьлары хәрәкәтләренең дошманлыгы тагын да күбрәк күренер.

Безнең тышкы сәүдәбезгә карата бу дошманлык актларын Советлар Союзы Германия белән сәүдә итеп аңа Англиягә һәм Франциягә каршы сугышуда ярдәм итә дип акларга маташулар булды. Бу дәлилләрнең сукыр бер тиенгә дә тормауларына ышану кыен түгел. Моның өчен СССР ны Румыния белән генә булса да чагыштырып карарга кирәк. Маглүм ки, Румыниянең тышкы бөтен товар оборотының яртысы Германия белән сәүдә итүдән тора, шуның өстенә Германиягә товар чыгаруда Румыниянең милли продукциясенең өлеше, мәсәлән, нефть продуктлары һәм ашлык кебек төп товарлар буенча, Германиягә безнең товар чыгаруыбызда СССР ның милли продукциясенең тоткан урыннан күп тапкырлар артып китә. Шулай булса да Румыния хөкүмәтенә карата Англия һәм Франция дошманлык актларына бармыйлар һәм Румыниядән Германия белән сәүдә итүне туктатуны таләп итәргә мөмкин дип санамыйлар. Советлар Союзына караш бөтенләй башкача. Димәк, Советлар Союзына карата Англиянең һәм Франциянең дошманлык актлары СССР белән Германиянең сәүдә итүеннән килеп чыкмыйлар, бәлки Германиягә каршы сугышта безнең илебездән файдалану турында Англия-Франция җитәкчеләренең исәпләре өзелгәнлектән һәм шуңа күрә Советлар Союзына карата аларның үч алу политикасы үткәрүләреннән килеп чыгалар.

Тагын шуны өстәргә кирәк, Англиянең һәм Франциянең бу дошманлык чыгышлары барсы да бу илләргә карата Советлар Союзы тарафыннан әлегә кадәр бер нинди дә дошманлык хәрәкәтләре ясалмауга да карамастан үткәрелеп килделәр. Кызыл Армиянең „Һиндстанга“, „көнчыгышка“ һ. б. ниндидер походлары турында Советлар Союзына карата әйтелгән хиялый планнар—шундый ачыктан-ачык күренеп тора торган кыргыйлык ки, моның кебек ахмак лыгырдауга бары тик бөтенләй акылдан язган кешеләр генә ышанырлар. **(Көлү).** Билгеле, эш монда түгел. Эш, күрәсең, Советлар Союзы үткәрә торган нейтралитет политикасының Англия-Франция җитәкчеләренең кәефенә ошамаган булуында. Шуның өстенә аларның нервлары да бик үк тәртиптә түгел, күрәсең. **(Көлү).** Алар безгә башка төрле политика—Германиягә каршы дошманлык һәм сугыш политикасын, үзләренә СССР дан империалистик максатлар өчен файдаланырга мөмкинлек бирерлек политика тагарга телиләр. Советлар Союзының бер кайчан да чит политика коралы булмаганлыгын һәм булмаячагын, башка илләрдәге әфәнделәргә ошавы яки ошамавы белән хисаплашмастан СССР үз политикасын үткәреп килгәнлеген һәм үткәрәчәген бу әфәнделәргә аңларга вакыт иде инде. **(Озакка сузылган көчле кул чабулар).**



Финляндия мәсьәләсенә күчәм.

Соңгы өч ай ярымнан артык вакыт буена Финляндиядә җәелеп киткән сугышның магнәсе нәрсәдә? Сез беләсез, бу вакыйгаләрнең магнәсе Советлар Союзының төньяк-көнбатыш чикләренә куркынычсызлык тәэмин итүдән һәм барыннан да элек Ленинградка куркынычсызлык тәэмин итүдән гыйбарәт иде.

Үткән елның октябрь һәм ноябрь айларында Совет хөкүмәте Финляндия хөкүмәте белән шундый такдимнәр турында сөйләшүләр алып барды, бу такдимнәрне торган саен кызып бара торган хәзерге халыкара шартларда тормышка ашыруны без илебезгә куркынычсызлык тәэмин итү өчен һәм бигрәк тә Ленинградка куркынычсызлыкны тәэмин итү өчен бик кирәк һәм кичектерергә ярамый дип санадык. Бу сөйләшүләрдән бер нәрсә дә чыкмады, чөнки Финляндия вәкилләре дусларча булмаган позициягә бастылар. Мәсьәләне хәл итү сугыш кырына күчерелде. Ышаныч белән әйтергә мөмкин, әгәр дә Финляндиягә карата тышкы йогынтылар булмаган булса иде, әгәр дә кайбер өченче дәүләтләрнең Финляндияне Советлар Союзына карата дошманлык политикасына котыртулары азрак булган булса иде, ул чагында Советлар Союзы һәм Финляндия үткән елның көзендә үк инде үзара килешкән булырлар иде һәм эш сугышсыз гына беткән булыр иде. Ләкин Совет хөкүмәтенең үзенең таләпләрен минимумга калдыруына да карамастан, эшне дипломатия юлы белән бетерергә мөмкин булмады.

Хәзер, Финляндиядә сугыш хәрәкәтләре беткәч һәм СССР белән Финляндия республикасы арасында солых договорына кул куелгач Финляндиядәге сугышның әһәмияте турында бәхәссез фактлар нигезендә хөкем йөртергә кирәк һәм мөмкин. Ә бу фактлар үзләреннән-үзләре күренеп торалар. Бу фактлар Финляндия властьларының Ленинград якынында гына, бөтен Карелия бугазында, 50-60 километр киңлектә артиллерия һәм пулеметлар белән коралландырып, күп санлы һәм куәтле тимер-бетон һәм гранит-балчык хәрби ныгытмалар ясаганлыкларын күрсәтәләр. Бу ныгытмалар күп йөзләрчә саналалар. Бу хәрби ныгытмалар, бигрәк тә хәрби яктан шактый куәтле булган, җир астыннан йөрү юллары булган, танкка каршы махсус чокырлары һәм гранит баганалары булган, күп санлы мина кырлары корылмалары белән сакланган тимер-бетон корылмалар бөтенесе бергә „Мажино линиясе“ һәм „Зигфрид линиясе“ типы буенча тиешле чит ил белгечләре җитәкчелегендә ясалган „Маннергейм линиясе“ дип аталган нәрсәдән гыйбарәт булганнар. Әйтергә кирәк, бу ныгытмалар безнең көннәргә кадәр алына алмаслык булып, ягни хәзергә кадәр әле бер армия тарафыннан да җимерелмәгән ныгытмалар булып саналып килделәр. Шулай ук әйтергә кирәк, финнәрнең хәрби властьлары бу районнардагы һәрбер авылны алдан ук кораллар белән, радио антенналары белән, ягулык колонкалары һ. б. белән тәэмин ителгән ныгытылган пунктка әйләндерергә тырышканнар. Көньяк һәм Көнчыгыш Финляндиянең күп кенә урыннарында безнең чигебезгә якын гына җиргә бер нинди дә хуҗалык әһәмияте булмаган стратегик тимер юллар һәм таш юллар үткәрелгән.

Кыска гына әйткәндә, Финляндия һәм барыннан да элек Карелия бугазы Советлар Союзына һөҗүм итү өчен, Ленинградка һөҗүм итү өчен 1939 нчы ел башында ук инде өченче дәүләтләргә әзер сугыш плацдармына әйләндерелгән булуын Финляндиядәге сугыш хәрәкәтләре күрсәттеләр.

Үткән елның көзендә безгә каршы куелган Финляндия политикасының дошманлыгы очраклы хәл булмаганлыкны ачык фактлар күрсәттеләр. Советлар Союзына дошман булган көчләр безнең илебезгә каршы һәм барыннан да элек Ленинградка каршы Финляндиядә шундый сугыш плацдармы хәзерләгәннәр ки, СССР өчен уңайсыз булган маглүм хәлләрдә бу плацдарм Финляндиядә советка каршы империалистларның һәм аларның союзникларының планнарында үзенең ролен уйнарга тиеш булган.

Кызыл Армия „Маннергейм линиясен“ җимереп һәм шуның белән иң кыен шартларда нак хәзерге заманча булган хәрби ныгытмаларның куәтле зур полосасы аркылы юл салган беренче армия сыйфатында үзен дан белән каплап кына калмады,—Кызыл Армия, Кызыл Флот белән бергәләп, Финляндиянең Ленинградка һөҗүм итү өчен хәзерләнгән сугыш плацдармын җимереп кенә калмады, бәлки соңгы елларда кайбер өченче илләр тарафыннан советка каршы хәзерләнеп килгән кайбер планнарны да җимерде. **(Озакка сузылган кул чабулар).**

Финляндиянең СССРга каршы сугыш плацдармы хәзерләгән җитәкче һәм хәрби даирәләрендә безнең илебезгә карата дошманлыкның никадәр тирән кергәнлеге яраланган һәм плен төшкән кызыл армеецларга карата ак финнәр тарафыннан эшләнгән күп санлы гадәттән тыш вәхшилек һәм ерткычлык фактларыннан да күренә. Мәсәлән, Ладога күленнән төньяктарак булган районнарның берсендә финнәр безнең санитария землянкаларыбызны чолгап алганнар, анда авыр яраланган 120 кеше булган, ак финнәр аларның барсын да юк иткәннәр, бер өлеше яндырылган, бер өлеше башлары җимерелгән хәлдә табылган, калганнарын кадап яки атып үтергәннәр. Үләрлек дәрәҗәдә яралары булуга да карамастан, башка урыннардагы кебек үк монда да һәлак булганнарның шактый өлешенең башларында өстәп ату һәм шуның өстенә прикладлар белән кыйнау эзләре булган, ә утлы корал белән үтерелгәннәрнең бер өлешендә йөзләренә фин пычаклары белән кадаудан калган эзләр булган. Кайбер үлек гәүдәләр башлары өзелгән килеш табылганнар һәм аларның башларын табып булмаган. Ак финнәр кулына эләккән санитарка хатын-кызларга карата махсус мыскыллаулар һәм коточкыч ерткычлыклар кулланылган. Кайбер хәлләрдә үтерелгәннәрнең гәүдәләре аякларын югары күтәртеп агачларга терәтеп куелганнар. Бу вәхшилекләр һәм исәпсез-сансыз ерткычлыклар барсы да—үзенең халкында безнең илебезгә карата дошманлык кабызырга омтылган фин ак гвардеецлары политикасының җимешләре.

„Көнбатыш цивилизация“не яклаучы финнәрнең йөзе әнә шундый.

Финляндиядәге сугышның просто фин гаскәрләре белән бәрелешү генә булмаганлыгын күрү кыен түгел. Юк, монда эш катлаулырак булды. Монда безнең гаскәрләребезнең просто фин гаскәрләре белән генә түгел, бәлки барлык корал төрләре белән һәм бигрәк тә артиллерия һәм самолетлар белән, шулай ук „доброволецлар“ исме астында үзләренең кешеләре белән, үзләренең алтыннары белән һәм һәр төрле кирәк-яраклар белән, Советлар Союзына каршы сугыш утын төрлечә көчәйтү өчен үзләренең бөтен дөньяда алып барган котырынган агитацияләре белән Финляндия буржуазиясенә ярдәм иткән күп кенә илләрдәге, шул исәптән, Англиядәге, Франциядәге империалистларның һәм башкаларның берләшкән көчләре белән бәрелешләре булды. Шуның өстенә әйтергә кирәк, Советлар Союзы дошманнарының ярсулы акырынуларында II нче Интернационалдагы проституткачылык итүче барлык „социалистларның“ **(залда күңелле җанлану)**, үзләрен сугыш уты кабызучыларга бөтенләйгә саткан, капитал лакейлары булган эттлиларның һәм блюмнарның, ситриннарның һәм жуоларның, транмельләрнең һәм хеглундларның чинаган тавышлары һәр вакыт аеруча ишетелеп торды.

Англиянең баш министре Чемберлен, 19 нчы мартта түбәнге палатада речь белән чыгып, Финляндиядә сугышны тәмам итүгә комачауларга мөмкин булмау уңае белән үзенең усал кайгыруын белдереп һәм шулай итеп үзенең „тынычлык сөючән“ империалистик йөрәген бөтен дөнья алдында әйләндереп күрсәтеп кенә калмады **(көлү)**, бәлки Советлар Союзына каршы Англия империалистларының Финляндиядә сугыш кабызуга ничек итеп һәм нәрсә белән ярдәм итәргә омтылганлыклары турында отчетсыман бер нәрсә дә бирде. Чемберлен Финляндиягә вагдә ителгән һәм җибәрелгән сугыш материалларының исемлеген иглан итте: 152 самолет вагдә ителгән, 101 самолет җибәрелгән; 223 орудие вагдә ителгән, 114 җибәрелгән; 297 мең снаряд вагдә ителгән, 185 мең җибәрелгән; 100 данә Виккерс пушкалары вагдә ителгән, 100 данә җибәрелгән; 20.700 авиация бомбасы вагдә ителгән, 15.700 җибәрелгән; танкка каршы 20.000 мина вагдә ителгән, 10.000 җибәрелгән һ. б. Чемберлен, һич тә оялмыйча, „экспедиция частьләрен җибәрүгә хәзерлекнең иң зур тизлек белән алып барылганлыгы һәм 100 мең кешелек экспедиция армиясенең март башында—аларның Финляндиягә килүләре өчен Маннергейм билгеләгән сроктан ике ай элек җибәрелергә хәзер булганлыгы... Бу гаскәрләр артыннан тагын да гаскәрләр җибәрелергә тиеш булачагы“ турында сөйләде.

Үзенең икрар итүенчә үк Англиянең „тынычлык сөюче“ империалисты эштә әнә шундый.

Инде Франциягә килсәк, Франция матбугатының язуына караганда, аннан Финляндиягә 179 самолет, 472 орудие, 795.000 снаряд, 5.100 пулемет, 200.000 кул гранатасы һ. б. җибәрелгән. Франциянең ул вакыттагы баш министре Даладье 11 нче мартта депутатлар палатасында болай дигән: „Франция Финляндиягә сугыш материаллары бирергә ризалык биргән илләрнең башында торды һәм аерым алганда, Франция, Гельсинкиның үтенүе буенча, әле яңа гына Финляндиягә үтә хәзерге заман бомбардировщиклары җибәрде“. Аннары Даладье болай дигән: „26 нчы февральдән башлап Франция гаскәрләренең экспедиция корпусы коралландырылды һәм хәзерлек хәленә китерелде. Күп кенә санлы караблар Ламанштагы һәм Атлантика буендагы ике зур порттан чыгып китәргә хәзер торалар“. Шулай ук Даладье, союзниклар „Финляндиягә барлык вагдә ителгән көчләр белән ярдәмгә килерләр“ дип белдергән.

Советлар Союзына Даладьеның дошман булган бу белдерүләре үзләре өчен үзләре сөйлиләр. Ләкин бу дошманлык белдерүләргә тукталып торуның кирәге юк, чөнки аларда фикерләрнең аек йөреше инде тулысынча юк, күрәсең. **(Залда күңелле җанлану).**

Аннан соң Финляндия сугышында Швециянең катнашуы турында искә алырга кирәк. Швециядәге барлык газеталарда да басылган хәбәрләргә караганда, Швеция Советлар Союзына каршы сугыш вактында Финляндия карамагына „маглүм санда самолетлар“ биргән, бу самолетлар „чама белән алганда, Швециянең ул чагындагы хәрби һава көчләренең биштән бер өлеше булганнар“. Швециянең сугыш министренең белдерүенчә финнәр Швециядән 84.000 винтовка, 575 пулемет, 300 дән артык артиллерия орудиеләре, 300 мең граната, 50 миллион патрон алганнар. Министрнең әйтүенчә бу материаллар барсы да иң соңгы үрнәктәге материаллар булганнар.

Финляндиядә сугышны кабызуда Италия дә артта калмады. Мәсәлән, ул Финляндиягә 50 хәрби самолеты җибәрде.

Шулай ук Финляндиягә сугыш ярдәме „тынычлык сөюне“ бик яратучы Америка Кушма Штатларыннан да килде. **(Барсы да көләләр).**

Сугыш вактында гына да башка илләрдән Финляндиягә җибәрелгән һәр төрле коралларның гомуми саны, тулы булмаган маглүматларга караганда, түбәндәге күләмнәргә җиткән: кимендә 350 самолет, 1.500 гә якын артиллерия орудиеләре, 6.000 нән артык пулемет, 100 меңгә якын винтовка, 650.000 кул гранатасы, 2.500.000 снаряд, 160.000.000 патрон һәм күп кенә тагын башка нәрсәләр.

(Ахры 2 нче биттә).

СССР НЫҢ I НЧЕ ЧАКЫРЫЛЫШ ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫНЫҢ АЛТЫНЧЫ СЕССИЯСЕ

ХӨКҮМӘТНЕҢ ТЫШКЫ ПОЛИТИКАСЫ ТУРЫНДА

Халык Комиссарлары Советы Председателе һәм Чит Ил Эшләре Халык Комиссары иптәш **В. М. Молотовның** 1940 нчы елның 29 нчы мартында ССР Союзы Верховный Советы утырышында ясаган доклады

(Ахры. Башы 1 нче биттә).

Финляндиядә эш безнең просто фин гаскәрләре белән бәрелешебез турында гына бармаганлыкны, бәлки Советлар Союзына карата аеруча дошман булган күп кенә империалистик илләрнең берләшкән көчләре белән бәрелеш булганлыкны раслый торган башка фактларны китереп торасы юк. Дошманнарның бу берләшкән көчләрен җимереп, Кызыл Армия һәм Кызыл Флот үзләренең тарихларына данлыклы яңа сәхифә яздылар һәм безнең халкыбызда батырлык, үз-үзеңне аямау һәм геройлык чыганагының бетмәслек булуын күрсәттеләр. **(Көчле кул чабулар).**

Финляндиядәге сугыш бездән дә, шулай ук финнәрдән дә зур корбаннар таләп итте. Безнен Генеральный Штабыбызның исәпләвенә караганда, безнең якта үтерелгәннәрнең һәм яраланудан үлгәннәрнең саны 48.745 кешегә җитә, ягни 49. мең кешедән азгына кимрәк, яраланганнар саны 158.863 кеше. Финнәр үзләренең корбаннарын киметеп күрсәтергә маташалар, ләкин финнәрнең корбаннары безнекеннән шактый күбрәк. Безнең Генеральный Штабыбызның минимум исәпләренә караганда, финнәр ягында үтерелүчеләр саны кимендә 60 меңгә җитә, бу исәпкә яраланудан үлгәннәр кермиләр, ә яраланучылар саны 250.000 кешедән дә ким түгел. Шулай итеп, Финляндия армиясе кимендә 600 мең кешедән торган дип исәпләгәндә, Финляндия армиясенең бөтен составының яртысыннан күбрәге үтерелгән һәм яраланган дип санарга кирәк.

Фактлар шундыйлар.

Бер сорау туа: ни өчен сон Англия һәм Франция, шулай ук башка кайбер илләрнең җитәкче даирәләре бу сугышта Финляндия ягыннан торып Советлар Союзына каршы шундый актив төстә катнаштылар. Маглүм ки, Англия һәм Франция хөкүмәтләре, Финляндиягә карата бер нинди йөкләмәләр белән дә бәйләнмәгән булсалар да, Финляндиядә сугышны бетерүгә һәм тынычлык урнаштыруга комачаулау өчен бөтен көчләрен биреп тырыштылар. Шулай ук маглүм ки, заманында, хәтта Франция белән Чех-Словакия арасында үзара ярдәмләшү пакты булуга да карамастан, Франция Чех-Словакиягә ярдәмгә килмәде. Финляндиягә килгәндә исә Франция дә, шулай ук Англия дә сугышны бетерүгә һәм Финляндия белән Советлар Союзы арасында тынычлык урнаштыруга җайсызлау өчен генә үзләренең хәрби ярдәмнәрен туп-туры көчләп тактылар. Газета аркылы жуликлык итүгә һәм ялганлауга специаллашкан һәр төрле язучылар арасындагы ялланган юлбасарлар Англия - Франция җитәкчеләренең үзләрен болай тотуларын „кечкенә халыклар" турында аеруча кайгыртучанлык белән аңлатырга маташалар. Ләкин Англиянең һәм Франциянең бу политикасын кечкенә дәүләтнең интереслары турында аеруча кайгыртучанлык белән аңлату просто көлке. Шулай ук аны гүяки үз членын яклауны таләп иткән Милләтләр Лигасы каршындагы йөкләмәләр белән аңлату да үтә акыллылык түгел.

Чыннан да, Милләтләр Лигасы члены булып торган бәйсез Албанияне Италиянең басып алуына һәм юк итүенә әле бер ел да үтмәде. Нәрсә булды соң? Англия һәм Франция Албанияне яклап чыктылармы, алар бер миллионнан артык булган халкы белән хисаплашмастан һәм Албаниянең Милләтләр Лигасы члены икәнлеген игтибарга алмастан, Албанияне үзенә көчләп буйсындырган Италиянең басып алу хәрәкәтләренә каршы йомшак кына булса да тавыш күтәрделәрме. Юк, Англия, Франция хөкүмәтләре дә, Америка Кушма Штатлары да, үзендә шул ук Англия - Франция империалистлары хуҗалык итү аркасында бөтен авторитетын югалткан Милләтләр Лигасы да бу уңай белән хәтта бармак та кыймылдатмадылар. Бу кечкенә халыкларны „яклаучылар", Милләтләр Лигасы членнарының хокуклары өчен бу „көрәшчеләр" нак 12 ай буена Италиянең үткән елның апрелендә үк Албанияне басып алуы турындагы мәсьәләне Милләтләр Лигасы тикшерүенә куярга һаман да батырчылык итмәделәр. Ул гына да түгел, асылда алар бу басып алуны санкцияләделәр. Димәк, Советлар Союзына каршы Англия һәм Франция җитәкчеләренең Финляндияне яклаулары һич тә кечкенә халыкларны яклау белән һәм Милләтләр Лигасы членнарының хокукларын яклау белән аңлатылмый. Бу булышлык аларның Финляндиядә СССР га һөҗүм булачакны күздә тотып хәзерләнгән сугыш плацдармнары булу белән, ә Албаниянең аларның планнарында андый урында тормавы белән аңлатыла. Чыннан да кечкенә халыкларның хокуклары һәм интереслары империалистлар кулында уенчык кына.

Англия империалистларының җитәкче газетасы „Таймс", шулай ук Франция империалистларының җитәкче газетасы „Тан", Англиядәге һәм Франциядәге башка буржуаз газеталар турында инде әйтеп тә тормастан, соңгы айларда, Англия һәм Франция белән Советлар Союзы арасында нормаль дипломатия мөнәсәбәтләре булу белән аз гына да хисаплашмастан, Советлар Союзына каршы ачыктан-ачык интервенциягә чакырдылар. Англиядәге Эттли тибындагы, Франциядәге Блюм тибындагы, сугыш кабызу һәм аны тагын да киңәйтү юлында бик тырышып эшләүче „социалистлар" өчен хәзер һәрбер „тәртипле" буржуаз дәүләттә төзелгән лакейлар бүлмәләре кешеләре шушы җитәкче буржуаз газеталарга ияреп һәм хәтта алардан да уздырып җибәреп речьләр белән чыгалар. Англия-Франция империалистик матбугатының һәм аның җырын җырлаучы шушы „социалистлар"ның чыгышларында социалистик дәүләтне дошман күрүче һәм безгә Советлар Союзы яши башлауның беренче көннәреннән үк таныш булган шул ук ерткыч империализм тавышы ишетелә. 1919 нчы елның 17 нче апрелендә үк Англиянең „Таймс" газетасы болай дип язган иде:

„Әгәр дә без картага карасак. Петроградка бара торган иң яхшы юл Балтык икәнлекне һәм аңа таба иң кыска һәм иң җиңел юл Финляндия аркылы икәнлекне күрәчәкбез, Финляндия чиге исә Россиянең башкаласыннан күп булса 30 миль ераклыкта гына тора. Финляндия—Петроградның ачкычы, ә Петроград—Москва ачкычы".

Англия һәм Франция империалистларының әле һаман да мондый акылдан язган планнарыннан аерылмаганлыкларына нинди булса да дәлилләр кирәк булган булса, Финляндиядәге соңгы вакыйгалардан соң инде бу турыдагы һәр төрле ачык булмаган яклар бетте. Тиешле планнарның яңадан җимерелүләре советка каршы Англиядәге һәм Франциядәге көчләрнең тырышлыклары җитәрлек булмау аркасында булмады, һәм соңгы моментта Финляндия, шулай ук Швеция һәм Норвегия җитәкчеләренең ахры чиктә маглүм дәрәҗәдә акыллылык күрсәткән булулары аркасында да булмады. Бу планнар Кызыл Армиянең, бигрәк тә Карелия бугазында бик яхшы уңышлары аркасында өзелделәр. **(Кул чабулар).** Ләкин без соңгы вакыйгаларнең безнең барыбызга да үзебезнең Кызыл Армиябезнең куәтен һәм илебезне саклау буенча бөтен эшне тагын да туктаусыз ныгытырга кирәклекне яңадан хәтерләтүләрен онытмабыз. **(Озакка сузылган көчле кул чабулар).**

Февраль башында финнәр Финляндиядә сугышны бетерү турындагы мәсьәләне практик төстә куйдылар. Безнең сугышны нинди шартларда бетерүебез мөмкин икәнлекне Финляндия хөкүмәтенең белергә теләгәнлеген без Швеция хөкүмәте аркылы белдек. Бу мәсьәләне хәл иткәнчегә кадәр без Финляндиянең халык хөкүмәтенә мөрәҗәгать итеп, бу мәсьәлә буенча аның фикрен сорадык. Халык хөкүмәте кан коюны туктату һәм Финляндия халкының хәлен җиңеләйтү теләге белән сугышны бетерү турындагы тәкъдимгә риза булырга кирәк дигән фикер ягында торды. Шуннан соң без үзебезнең шартларны куйдык һәм озак та үтми Финляндия хөкүмәте аларны кабул итте. Мин шуны өстәргә тиешмен, финнәр белән сөйләшүләр башланганнан соң бер атна үткәч Англия хөкүмәте дә Финляндиядә сугышны бетерү теләге белән дигән булып арадашлык итү мөмкинлеген белергә теләвен әйтте. **(Көлү)**, ләкин Англиядәге безнең полпредыбыз иптәш Майский безнең соңыннан Финляндия тарафыннан тулысынча кабул ителгән тиешле тәкъдимнәребез турында Лондонда информация ясаганнан соң Англия хөкүмәте сугышны бетерүгә һәм СССР белән Финляндия арасында тынычлык урнаштыруга булышлык итәргә теләмәде. Шулай булса да СССР белән Финляндия арасында тиздән килешү булды. Сугыш хәрәкәтләрен туктату турындагы һәм тынычлык урнаштыру турындагы килешүнең нәтиҗәләре 12 нче мартта кул куелган солых договорында күренделәр. Шул уңай белән халык хөкүмәтенең үзен-үзе тарату турындагы мәсьәлә килеп басты һәм бу хөкүмәт моны тормышка ашырды.

Сез, солых договоры куйган шартларны беләсез. Бу договор буенча Финляндиянең көньяк һәм бер кадәр көнчыгыш чикләре үзгәртелде. Выборг шәһәре һәм Выборг заливы белән берлектә бөтен Карелия бугазы, Кексгольм һәм Сортавала белән берлектә Ладога күленең бөтен көнбатыш һәм төньяк яры Советлар Союзына күчте. Кандалакша районында, Финляндия чиге Мурманск тимер юлына аеруча якын килә торган урында чик үзгәртелде. Төньякта Финляндия кулында булган Средний һәм Рыбачий ярым атауларының кечрәк өлешләре, ә Фин заливында Гогланд атавы белән берлектә маглүм атаулар группасы Советлар Союзына күчте. Шуның өстенә Советлар Союзына, аренда тәртибендә, 30 ел срок белән, Советлар Союзының ел саен 8 миллион фин маркасы түләве шарты белән Ханко ярым атавы һәм аңа караган атаулар күчтеләр, монда Фин заливына керү юлын агрессиядән саклау өчен безнең хәрби диңгез базасы төзеләчәк. Шуның белән бергә, договор Швеция, Норвегия һәм Советлар Союзы өчен товарлар үткәрү мөмкинлеген җиңеләйтә. Шулай ук солых договоры берберенә һәр төрле һөҗүмнән тыелып калуны һәм бер-беренә дошман булган коалицияләрдә катнашмауны күздә тота.

Англия - Франция матбугатында Совет - Финляндия договорын һәм аерым алганда Карелия бугазының Советлар Союзына күчүен Финляндиянең бәйсезлеген „югалту" дип күрсәтергә маташулар булды. Билгеле, бу—кыргыйлык һәм бушка лыгырдау! Финляндия хәзердә дә Венгриядән дүрт тапкыр диярлек, Швейцариядән сигез тапкырдан күбрәк зур булган территория. Әгәр дә Венгриянең һәм Швейцариянең бәйсез дәүләтләр булуына бер кем дә шикләнми икән, Финляндиянең бәйсез һәм суверенитетлы икәнлегенә шикләнергә мөмкинме соң.

Шул ук Англия - Франция матбугатында, Советлар Союзы гүяки Финляндияне бары тик Балтык буе дәүләтенә генә әйләндерергә тели дип яздылар. Билгеле, бу да ахмаклык. Сугыш вактында Боз океанына күрше булган Петсамо районын алганнан соң СССР ның бу районны яңадан үз ирке белән Финляндиягә кайтарып биргәнлеген генә күрсәтү дә җитә, чөнки ул Финляндиягә катмый торган океан порты бирергә кирәк дип санады. Монардан без Финляндияне Балтык буе иле дип кенә түгел, бәлки төньяк иле дип тә санаыйбыз дигән нәтиҗә килеп чыга.

Хаклык, советка каршы һәр төрле ялган пропаганда белән эш итәргә остарган Англия-Франция газеталарының бу уйдырмаларында түгел. Хаклык башка нәрсәдә, ягни ул шунда ки, фин армиясен җимергән һәм бөтен Финляндияне алырга тулы мөмкинлеге булган Советлар Союзы моңа бармады һәм үзенең сугыш расходларын каплау өчен бер нинди контрибуция таләп итмәде, бәлки Финляндиягә карата киң күңеллелек күрсәтеп, үзенең теләкләрен минимум белән чикләде, ә башка һәрбер дәүләт контрибуция салган булыр иде.

Солых договорының төп магнәсе нәрсәдә? Аның Ленинградка, шулай ук Мурманскига һәм Мурманск тимер юлына тиешенчә куркынычсызлык тәэмин итүендә. Бу юлы без үткән елның көзендә үз тарафыбыздан куелган һәм әгәр дә Финляндия кабул итсә сугышның башланмавына сәбәп булачак булган теләкләр белән генә чикләнә алмадык. Бездән булмаган сәбәпләр аркасында безнең сугышчыларыбызның каны коелганнан соң һәм Советлар Союзына карата Финляндия хөкүмәте политикасының дошманлыгы никадәр тирән кергәнлеккә ышанганнан соң без Ленинградка куркынычсызлык турындагы мәсьәләне тагын да ышанычлырак нигезгә куярга тиеш булдык һәм шуның өстенә Мурманск тимер юлына һәм көнбатышта безнең бердәнбер катмый торган һәм шуна күрә дә безнең тышкы сәүдәбез өчен һәм гомумән Советлар Союзының башка илләр белән элемтәсе өчен гаять зур әһәмияте булган портыбыз булган Мурманскига куркынычсызлык турындагы мәсьәләне куярга тиеш булдык. Солых договорында без Ленинградка, Мурманскига һәм Мурманск тимер юлына куркынычсызлыкны тәэмин итүдән башка бер нинди дә бүтән теләкләр куймадык. Ләкин аның каравы без бу мәсьәләне ышанычлы һәм ныклы рәвештә хәл итәргә кирәк дип санадык. Солых договоры Финляндиянең дәүләт бәйсезлеге принципын танудан, аның тышкы һәм эчке политикасының мостәкыйльлеген танудан һәм шуның белән бергә Ленинградка һәм Советлар Союзының төньяк-көнбатыш чикләренә куркынычсызлыкны тәэмин итәргә кирәклектән чыгып эш итә.

Шулай итеп, без үзебез куйган теләккә ирештек һәм без Финляндия белән төзелгән договордан тәмам канәгатьләнү белдерә алабыз. **(Кул чабулар).**

Моннан соң Финляндия белән политик һәм хуҗалык мөнәсәбәтләре тулысынча яңартылалар. Хөкүмәт Советлар Союзы белән Финляндия арасында нормаль яхшы күршелек мөнәсәбәтләре үсәр дип ышаныч белдерә.

Ләкин төзелгән солых договорын Финляндиядәге, шулай ук Швециядәге һәм Норвегиядәге кайбер даирәләрнең бу илләр арасында хәрби-оборона союзы төзү сылтавы астында бозарга маташулары барлыкны кисәтеп куярга кирәк. Тарихи мисальләрне сылтау итеп китереп, „ил чикләрен яңадан яулап алуга" Финляндияне чакырган һәм Финляндия белән СССР арасында төзелгән солыхны „озак яши алмаячак" дип күрсәткән Норвегия стортингы председателе Хамбро әфәндененең күптән түгел сөйләгән речена һәм башка шундый чыгышларга карап, Финляндиянең, Швециянең һәм Норвегиянең „оборона союзы" дип аталган нәрсә төзергә маташуларының СССР га каршы юнәлдерелгәнлеген һәм сугыш ягыннан үч алу (реванш) идеологиясе белән акылсыз рәвештә көчәйтелүен аңлау кыен түгел. Финляндия катнашы белән мондый союзны төзү солых договорының договор төзүче якларның бер-беренә дошман булган коалицияләрдә (союзларда) катнашуларына юл куймаучы 3 нче статьясенә каршы килеп кенә калмас иде, бәлки Совет-Финляндия чиген нык итеп билгеләгән бөтен солых договорына каршы килер иде. Бу договорга турылыклы булу Финляндиянең СССР га каршы сугыш ягыннан нинди булса да үч алу союзына катнашуы белән бергә сыеша алмый. Мондый союзда Швециянең һәм Норвегиянең катнашуы исә бу илләрнең үзләре тарафыннан үткәрелә торган нейтралитет политикасыннан баш тартулары һәм аларның башка төрле тышкы политикага күчүләре дигән сүз булыр иде. Монардан Советлар Союзы үзенең тиешле нәтиҗәләрен чыгармый кала алмас иде.

Үз чиратында хөкүмәт Советлар Союзының Швеция белән һәм Норвегия белән бәхәсле мәсьәләләре юк дип һәм Совет - Швеция һәм Совет - Норвегия мөнәсәбәтләре дуслык нигезендә үсәргә тиеш дип саный. Советлар Союзы гүяки Скандинавиянең көнбатыш ярында үзенә портлар таләп итә дип, ул Нарвикны дәгъвали һ. б. дип советка каршы максатлар белән таратыла торган хәбәрләр исә шундый кыргыйлык ки, аны кире кагып торасы да юк. Швециядәге Хеглунд һәм Норвегиядәге Транмель кебек „социалист" әфәнделәрнең бу илләр белән Советлар Союзының мөнәсәбәтләрен бозарга тырышуларын исә чит ил капиталистлары тарафыннан сатып алынган һәм үз халыкларының интересларын сатучы кешеләрнең, эшчеләр сыйнфының иң явыз дошманнарының эше дип тамгаларга кирәк.

Финляндия белән солых договоры төзү Балтык диңгезе ягыннан Советлар Союзына куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча үткән елны куелган бурычларның үтәлүен төгәлли. Бу договор Эстония, Латвия һәм Литва белән үзара ярдәмләшү турында төзелгән 3 договорга кирәкле өстәмә булып тора. Үзара ярдәмләшү турындагы бу договорлар төзелгән вакыттан бирле үткән ярты еллык тәҗрибә нигезендә Балтык буе илләре белән төзелгән договорлар турында тулысынча маглүм булган яхшы нәтиҗәләрне ясарга мөмкин. Әйтергә кирәк, Советлар Союзының Эстония белән, Латвия белән һәм Литва белән төзегән договорлары Советлар Союзының да, шулай ук Эстониянең, Латвиянең һәм Литваның да халыкара позицияләре ныгуга ярдәм иттеләр. Советлар Союзына дошман булган империалистик даирәләрнең куркытуларына да карамастан, Эстониянең, Латвиянең һәм Литваның дәүләт бәйсезлеге һәм политикаларының мостәкыйльлеге бер яктан да зыян күрмәде, ә Советлар Союзы белән бу илләрнең хуҗалык мөнәсәбәтләре сизелерлек киңәя башлады. Эстония, Латвия һәм Литва белән төзелгән договорларның үтәлүе канәгатьләнерлек бара һәм Советлар Союзы белән бу дәүләтләр арасындагы мөнәсәбәтләрне тагын да яхшырту өчен шартлар тудыра.

Соңгы вакытларда чит ил матбугатында Советлар Союзының көньяк чиктәге күршеләре белән, аерым алганда Закавказьедәге күршеләре белән, шулай ук Румыния белән мөнәсәбәтләре турындагы мәсьәләгә гаять зур игтибар бирелде. Көньякта да күршеләребез белән мөнәсәбәтләрне начарлату өчен хөкүмәтнең бер нинди дә нигезләр күрмәвен исбат итеп торасы юк. Дөрес, хәзер Сүриядә һәм гомумән Якын Көнчыгышта генерал Вейган җитәкчелегендә Англия-Франция армияләре, күбесенчә колониаль армияләр төзү буенча зур шикле эш алып барыла. Советлар Союзына карата дошманлык теләкләре белән бу колониаль һәм колониаль булмаган гаскәрләрдән файдаланырга маташуларга карата без уяу торырга тиешбез. Моның кебек һәр төрле маташулар агрессорларга каршы безнең тарафтан җавап чаралары китереп чыгарырлар иде, шуның белән бергә, болай ут белән шаяруның куркыныч икәнлеге СССР га дошман булган державалар өчен һәм СССР га каршы бу агрессив политика коралы булып чыккан күршеләребез өчен тәмам ачык булырга тиеш. **(Кул чабулар).** Төркия һәм Иран белән безнең мөнәсәбәтләребезгә килсәк, алар һөҗүм итешмәү турында безнең арабызда булган тиешле договорлар белән һәм Советлар Союзының моннан килеп чыга торган үзара йөкләмәләрне үтәүгә тайпылышсыз омтылуы белән билгеләнәләр. Хуҗалык өлкәсендә Иран белән безнең мөнәсәбәтләребез әле яңа гына төзелгән Совет - Иран сәүдә договоры белән тәртипкә салындылар.

Мин әйтеп киткән көньяк күрше дәүләтләрдән Румыния белән безнең һөҗүм итешмәү турында пактыбыз юк. Бу хәл ителмәгән бәхәсле бер мәсьәлә, Бессарабия турындагы мәсьәлә булу белән аңлатыла. Румыниянең Бессарабияне басып алуын Советлар Союзы бер кайчан да танымады, хәер Бессарабияне сугыш юлы белән кайтарып алу турындагы мәсьәләне дә бер кайчан да куймады.

Шуңа күрә дә Совет - Румыния мөнәсәбәтләренең дә ни дәрәҗәдә булса да начарлануына бер нинди дә нигезләр юк. Дөрес, бик күп вакытлардан бирле Румыниядә безнең тулы хокуклы вәкилебез юк һәм аның хезмәтләрен СССР ның ышанычлысы башкара. Ләкин бу хәл үткән замандагы специфик хәлләрдән килеп чыкты. Бу мәсьәләгә кагылганда 1938 нче елны Румыниядә Совет полпреды хезмәтләрен үтәгән Бутенкога карата Румыния властьларының үзләрен начар тотканлыклары турында искә төшереп үтәргә кирәк. Маглүм ки, Бутенко ниндидер юл белән ул чагында полпредлыктан гына түгел, бәлки Румыниядән дә серле рәвештә юкка чыккан иде һәм Совет хөкүмәте бу юкка чыгу турында һаман да ышанычлы бер нәрсә дә белә алмады, шуның белән бергә без Румыниянең бер нинди властьларының да бу җинаятле-скандаллы эшкә катнашлары булмаганлыкка гүяки ышанырга тиеш булабыз. Культуралы дәүләттә һәм гомумән азмы-күпме төзек булган илдә мондый нәрсәләргә урын булмаска тиешлеген әйтеп тә торасы юк. Шушыннан соң инде Румыниягә Совет полпреды билгеләүнең ни өчен шулай озакка сузылган булуы аңлашыла. Ләкин шулай да Румыния мондый нәрсәләргә түзеп торырга мөмкин түгеллекне аңлар дип уйларга кирәк.

Япония белән мөнәсәбәтләребездә без бер кадәр кыенлыклар белән булса да кайбер мәсьәләләрне хәл иттек. Моны шушы елга балык тоту мәсьәләсе буенча үткән елның 31 нче декабрендә төзелгән Совет - Япония килешүе, шулай ук Япониянең КВЖД өчен озак вакытлар тоткарлап килгән соңгы акча взносын түләргә риза булуы күрсәтеп тора. Шулай булса да безнең Япония белән булган мөнәсәбәтләребездән зур канәгатьләнү белдереп булмый. Мәсәлән, Совет - Монголия һәм Япония - Манжурия делегатларының озак дәвам иткән сөйләшүләренә дә карамастан, үткән елны булган сугыш конфликты районында территориянең бер өлешендә чик билгеләү турындагы әһәмиятле мәсьәлә хәл ителми калды. Япония властьлары КВЖД өчен Япония тарафыннан кертелгән соңгы акча взносын нормаль төстә файдалануга тоткарлык ясауларында дәвам итәләр. Япониядәге һәм Манжуриядәге Совет органнары сотрудникларына карата Япония властьларының карашлары күп кенә хәлләрдә һич тә нормаль түгел. Советлар Союзының үзенең интересларын бозуга һичбер хәлдә дә юл куймаячагын Япониядә аңларга тиешләр инде. **(Озакка сузылган кул чабулар).** Совет-Япония мөнәсәбәтләрен шулай аңлаганда гына алар канәгатьләнерлек бара алачаклар.

Япония уңае белән, әйтик, эшкә кагылышы булмаган бер мәсьәлә буенча бер - ике сүз әйтәм. **(Залда күңелле җанлану).** Шушы көннәрдә Япония парламенты депутатларыннан берсе үзенең хөкүмәтенә шушындый сорау биргән: „СССР белән Япония арасындагы конфликтларны ничек итеп бетерергә, мәсәлән, Приморьены һәм башка территорияләрне сатып алу юлы белән ничек итеп тамырыннан бетерергә икәнлекне уйлап карарга кирәк түгелме икән". **(Шаркылдап көләләр).** Сатылмый торган Совет территорияләрен сатып алу белән кызыксынучы **(көлү)** һәм шушы сорауны биргән япон депутаты ким куйганда бик күңелле кеше. **(Көлү, кул чабулар).** Ләкин, минемчә, ул үзенең ахмак сораулары белән үз парламентының дәрәҗәсен күтәрми. **(Көлү).** Шулай да әгәр дә Япония парламентында сәүдә белән бу кадәр нык кызыксыналар икән, бу парламентның депутатлары Көньяк Сахалинны сатмаслар микән. **(Көлү, озакка сузылган кул чабулар).** СССР да сатып алучылар табылачагына мин шикләнмим. **(Көлү, кул чабулар).**

Америка Кушма Штатлары белән мөнәсәбәтләргә килсәк, соңгы вакытларда, бу мөнәсәбәтләр яхшырмадылар һәм СССР га каршы бигрәк тә СССР белән Финляндия арасында солых төзелгәннән соң бер нинди дә магнәсе булмаган „мораль эмбарго" дип аталган нәрсәне исәпкә алмаганда, ихтимал начарланмагандыр да. АКШ тан товар алуыбыз үткән ел белән чагыштырганда артты. Әгәр дә Америка властьлары тоткарлык ясамаган булсалар ул тагын да арткан булыр иде.

Соңгы биш ай эчендә булган вакыйгалар уңае белән халыкара хәлләр гомумән алганда әнә шундый.

Югарыда әйтелгәннәрнең барсыннан да безнең хәзерге халыкара шартларда үзебезнең тышкы политикабызның төп бурычларын нәрсәдән гыйбарәт дип санавыбыз күренә.

Кыска гына әйткәндә, безнең тышкы политикабызның бурычлары халыклар арасында тынычлыкны һәм илебезгә куркынычсызлыкны тәэмин итүдән гыйбарәт. Моннан, нейтралитет позициясе һәм Европаның зур дәүләтләре арасындагы сугышка катнашмау дигән нәтиҗә килеп чыга. Бу позиция без төзегән договорларга нигезләнгән һәм ул Советлар Союзының интересларына тулысынча туры килә. Шуның белән бергә, бу позиция Европада сугышны киңәйтүгә һәм көчәйтүгә тоткарлык итәрлек йогынты ясый һәм шуңа күрә ул тынычлыкка омтылучы һәм хәзер инде сугыш аркасында килеп чыккан гаять зур яңа мохтаҗлыклар астында ыңгырашучы барлык халыкларның интересларын күздә тота.

Соңгы чорга йомгак ясаганда без илебезгә куркынычсызлыкны тәэмин итү эшендә бу вакыт эчендә күп кенә уңышларга ирешкәнлегебезне күрәбез. Безнең дошманнарыбыз шуңа котыралар да. Без исә үзебезнең эшебезгә һәм үзебезнең көчләребезгә ышанган хәлдә, үзебезнең тышкы политикабызны туктаусыз һәм тагын да бөтен эзлеклелек белән дәвам итәрбез.

(Бөтен зал озак һәм көчле кул чаба. Депутатлар аякка басалар).

СССР НЫҢ I НЧЕ ЧАКЫРЫЛЫШ ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫНЫҢ АЛТЫНЧЫ СЕССИЯСЕ

СОЮЗ СОВЕТЫ УТЫРЫШЫ ТУРЫНДА ИНФОРМАЦИОН БЕЛДЕРҮ

29 март, 1940 ел

29 нчы мартта, көндез 2 сәгаттә Кремльдә, СССР Верховный Советының утырышлар залында Союз Советының Алтынчы Сессиясе ачылды.

Сессияне Союз Советы Председателе депутат **А. А. Андреев** ача.

Иптәш **А. А. Андреев** депутат **А. М. Алемасовка** сүз бирә. Депутат Алемасов Сегизбаевны хәзерге вакытта Үзбәкстан ССР да эшләмәве сәбәпле Союз Советы Председателе урынбасары хезмәтләреннән азат итү турында Үзбәкстан ССР депутатларының мәсьәлә куйганлыкларын белдерә. Союз Советының өлкәннәр Советы исеменнән депутат Алемасов Сегизбаевны Союз Советы Председателе урынбасары хезмәтләреннән азат итәргә һәм Союз Советы Председателе урынбасары итеп депутат **Усман Юсуповны** сайларга такдим кертә.

Депутат Алемасов керткән такдимне Союз Советы бер тавыштан кабул итә.

Иптәш **Андреевның** чакыруы буенча депутат **Усман Юсупов** Союз Советы Председателе өстәле артындагы урынга утыра.

Иптәш **Андреев** Сессиягә Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләреннән Союз Советына сайланган депутатлар килгәнлекне белдерә һәм Мандат Комиссиясенең доклады өчен депутат **А. С. Щербаковка** сүз бирә.

Иптәш **Щербаков** Союз Советына Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләреннән сайланган депутатларның полномочиеләрен тикшерүнең нәтиҗәләре турында Союз Советының Мандат Комиссиясенең карарын иглан итә:

„Һәрбер депутатка булган барлык сайлау документларын һәм Союз Советына Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләреннән сайлаулар буенча округ күләмендәге сайлау комиссияләре тарафыннан бирелгән барлык материалларны аерым рәвеш тә тикшереп, Союз Советының Мандат Комиссиясе түбәндәгеләрне билгели:

1. Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләрендә 43 сайлау округының барсында да Союз Советына депутатлар сайлау СССР Конституциясе һәм „СССР Верховный Советына сайлаулар турындагы положение“ нигезендә һәм шуларга тулысынча туры китереп үткәрелгән.

2. Сайлауларны дөрес түгел дип табарга һичбер төрле нигез юк, шулай ук Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләреннән Союз Советына депутатлар сайлаганда нинди булса да сайлау округында СССР Конституциясен һәм сайлаулар турындагы положениене бозулар турында һичбер жалоба һәм белдерү юк.

Шушы әйтелгәннәр нигезендә, Союз Советының Мандат Комиссиясе Союз Советына Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләреннән сайланган һәм исемлекләре „Известия“ нең 1940 нчы ел 28 нче мартындагы 72 нче номерында иглан ителгән депутатларының барсының да полномочиеләрен дөрес дип таба“.

Депутат **В. В. Верендякинның** такдиме буенча Союз Советы Мандат Комиссиясенең доклады буенча түбәндәге карарны кабул итә:

„СССР Верховный Советына сайлаулар буенча Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләрендәге 43 сайлау округының барсыннан да Союз Советына сайланган депутатларның полномочиеләрен дөрес дип табу турында Мандат Комиссиясенең докладын расларга“.

Союз Советы исеменнән иптәш **Андреев**, көчле кул чабулар һәм алкышлар астында, яңа иптәшләрне—СССР Верховный Советы депутатларын, Украинаның һәм Белоруссиянең көнбатыш өлкәләрендәге халыкларның вәкилләрен котлый.

Аннары Союз Советы Сессиянең көн тәртибен билгеләүгә күчә.

Иптәш **Андреев** Союз Советының Алтынчы Сессиясе каравына кертелгән мәсьәләләрне иглан итә.

Депутат **А. С. Пирузян** Союз Советы каравына кертелгән мәсьәләләрне Союз Советының Алтынчы Сессиясенең көн тәртибенә кертергә такдим итә.

Союз Советы түбәндәге көн тәртибен бер тавыштан раслый:

1. Хөкүмәтнең тышкы политикасы турында доклад.

2. Карелия Автономияле Совет Социалистик Республикасын Союзный Карель-Фин Совет Социалистик Республикасы итеп үзгәртеп кору.

СССР Совнаркомы тарафыннан кертелә.

3. СССР ның 1940 нчы елгы дәүләт бюджетын раслау һәм СССР ның 1938 нче елгы дәүләт бюджетының үтәлеше турындагы отчетны раслау.

СССР Совнаркомы тарафыннан кертелә.

4. СССР Верховный Советы Президиумының Сессияләр арасында кабул ителгән һәм СССР Верховный Советы расларга тиеш булган указларын раслау турында.

Депутат **Г. Г. Кузнецовның** такдиме буенча Союз Советы түбәндәге карарны кабул итә: хөкүмәтнең тышкы политикасы турындагы докладны һәм Сессия көн тәртибенең икенче мәсьәләсен—Карелия Автономияле Совет Социалистик Республикасын Союзный Карель-Фин Совет Социалистик Республикасы итеп үзгәртеп кору турындагы мәсьәләне ике палатаның берләштерелгән утырышында тыңлап тикшерергә; СССР ның 1940 нчы елгы дәүләт бюджеты турындагы докладны да ике палатаның берләштерелгән утырышында тыңларга; бюджет комиссияләренең өстәмә докладларын, дәүләт бюджетын тикшерүне һәм карарлар кабул итүне палаталарның аерым утырышларында үткәрергә; шулай ук Сессия көн тәртибенең дүртенче мәсьәләсен дә палаталарда тыңлап тикшерергә.

Шуның белән Союз Советының Алтынчы Сессиясенең беренче утырышы ябыла.

МИЛЛӘТЛӘР СОВЕТЫ УТЫРЫШЫ ТУРЫНДА ИНФОРМАЦИОН БЕЛДЕРҮ

29 март, 1940 ел

29 нчы мартта, көндез 4 сәгатьтә Кремльдә, СССР Верховный Советының утырышлар залында Милләтләр Советының Алтынчы Сессиясе ачылды.

Сессияне Милләтләр Советы Председателе депутат **Н. М. Шверник** ача.

Иптәш **Н. М. Шверник** депутат **Т. Т. Якуповка** сүз бирә. Милләтләр Советының өлкәннәр Советы исеменнән депутат Якупов Милләтләр Советы Председателе урынбасары депутат Левицкийны, Белоруссия ССР дан тыш башка эшкә күчүе сәбәпле, Милләтләр Советы Председателе урынбасары хезмәтләреннән азат итәргә һәм Милләтләр Советы Председателе урынбасары итеп депутат **М. В. Кулагинны** сайларга такдим кертә.

Милләтләр Советы депутат Якупов керткән такдимне бер тавыштан кабул итә.

Иптәш **Шверникның** чакыруы буенча депутат **Кулагин** Милләтләр Советы Председателе өстәле артындагы урынга утыра.

Иптәш **Шверник** Сессиягә Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләреннән Милләтләр Советына сайланган депутатлар килгәнлекне белдерә һәм Мандат Комиссиясенең доклады өчен депутат **М. А. Бурмистенкога** сүз бирә.

Иптәш **Бурмистенко** Милләтләр Советына Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләреннән сайланган депутатларның полномочиеләрен тикшерүнең нәтиҗәләре турында Милләтләр Советының Мандат Комиссиясенең карарын иглан итә:

„Һәрбер депутатка булган барлык сайлау документларын һәм Милләтләр Советына Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләреннән сайлаулар буенча округ күләмендәге сайлау комиссияләре тарафыннан бирелгән барлык материалларны аерым рәвештә тикшереп, Милләтләр Советының Мандат Комиссиясе түбәндәгеләрне билгели:

1. Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләрендә 12 сайлау округының барсында да Милләтләр Советына депутатлар сайлау СССР Конституциясе һәм „СССР Верховный Советына сайлаулар турындагы положение“ нигезендә һәм шуларга тулысынча туры китереп үткәрелгән.

2. Сайлауларны дөрес түгел дип табарга һичбер төрле нигез юк, шулай ук Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләреннән Милләтләр Советына депутатлар сайлаганда нинди булса да сайлау округында СССР Конституциясен һәм сайлаулар турындагы положениене бозулар турында һичбер жалоба һәм белдерү юк.

Шушы әйтелгәннәр нигезендә, Милләтләр Советының Мандат Комиссиясе Милләтләр Советына Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләреннән сайланган һәм исемлекләре „Известия“ нең 1940 нчы ел 28 нче мартындагы 72 нче номерында иглан ителгән депутатларының барсының да полномочиеләрен дөрес дип таба“.

Депутат **А. И. Гикманның** такдиме буенча Милләтләр Советы Мандат Комиссиясенең доклады буенча түбәндәге карарны кабул итә:

„СССР Верховный Советына сайлаулар буенча Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләрендәге 12 сайлау округының барсыннан да Милләтләр Советына сайланган депутатларның полномочиеләрен дөрес дип табу турында Мандат Комиссиясенең докладын расларга“.

Милләтләр Советы исеменнән иптәш **Шверник**, көчле кул чабулар һәм алкышлар астында, яңа иптәшләрне—СССР Верховный Советы депутатларын, Украинаның һәм Белоруссиянең көнбатыш өлкәләрендәге халыкларның вәкилләрен котлый.

Аннары Милләтләр Советы Сессиянең көн тәртибен билгеләүгә күчә.

Иптәш **Шверник** Милләтләр Советының Алтынчы Сессиясе каравына кертелгән мәсьәләләрне иглан итә.

Депутат **М. И. Ибраимов** Милләтләр Советы каравына кертелгән мәсьәләләрне Милләтләр Советының Алтынчы Сессиясенең көн тәртибенә кертергә такдим итә.

Милләтләр Советы түбәндәге көн тәртибен бер тавыштан раслый:

1. Хөкүмәтнең тышкы политикасы турында доклад.

2. Карелия Автономияле Совет Социалистик Республикасын Союзный Карель-Фин Совет Социалистик Республикасы итеп үзгәртеп кору.

СССР Совнаркомы тарафыннан кертелә.

3. СССР ның 1940 нчы елгы дәүләт бюджетын раслау һәм СССР ның 1938 нче елгы дәүләт бюджетының үтәлеше турындагы отчетны раслау.

СССР Совнаркомы тарафыннан кертелә.

4. СССР Верховный Советы Президиумының Сессияләр арасында кабул ителгән һәм СССР Верховный Советы расларга тиеш булган указларын раслау турында.

Депутат **Т. А. Константиновның** такдиме буенча Милләтләр Советы түбәндәге карарны кабул итә: хөкүмәтнең тышкы политикасы турындагы докладны һәм Сессия көн тәртибенең икенче мәсьәләсен—Карелия Автономияле Совет Социалистик Республикасын Союзный Карель-Фин Совет Социалистик Республикасы итеп үзгәртеп кору турындагы мәсьәләне ике палатаның берләштерелгән утырышында тыңлап тикшерергә; СССР ның 1940 нчы елгы дәүләт бюджеты турындагы докладны да ике палатаның берләштерелгән утырышында тыңларга; бюджет комиссияләренең өстәмә докладларын, дәүләт бюджетын тикшерүне һәм карарлар кабул итүне палаталарның аерым утырышларында үткәрергә; шулай ук Сессия көн тәртибенең дүртенче мәсьәләсен дә палаталарда тыңлап тикшерергә.

Шуның белән Милләтләр Советының Алтынчы Сессиясенең беренче утырышы ябыла.

СОЮЗ СОВЕТЫНЫҢ ҺӘМ МИЛЛӘТЛӘР СОВЕТЫНЫҢ БЕРЛӘШТЕРЕЛГӘН УТЫРЫШЫ ТУРЫНДА ИНФОРМАЦИОН БЕЛДЕРҮ

29 март, 1940 ел

29 нчы мартта кич 7 сәгаттә, Кремльдә СССР Верховный Советының утырышлар залында Союз Советының һәм Милләтләр Советының берләштерелгән беренче утырышы булды.

Утырышта Союз Советы Председателе депутат **А. А. Андреев** председательлек итә.

Утырыш ачылыр алдыннан иптәш **А. А. Андреевнең** такдиме буенча СССР Верховный Советы ак финнәргә каршы сугышларда һәлак булган һәм Ватаныбызның куркынычсызлыгын тәэмин итү эшенә үзләренең тормышларын биргән Кызыл Армия сугышчыларын урыннан торып искә алды.

Аннары СССР Верховный Советы Сессия көн тәртибенең беренче пунктын карауга керешә.

Хөкүмәтнең тышкы политикасы турындагы докладны СССР Халык Комиссарлары Советы Председателе һәм Чит Ил Эшләре Халык Комиссары иптәш **В. М. Молотов** ясады. Депутатлар аны озакка сузылган көчле алкышлар белән каршы алдылар.

Иптәш Молотов доклады беткәннән соң, депутат **М. Д. Багиров** түбәндәге такдимне кертә: СССР хөкүмәтенең тышкы политикасы тулысынча ачык һәм эзлекле булганлыктан, СССР Халык Комиссарлар Советы Председателе һәм Чит Ил Эшләре Халык Комиссары иптәш Молотов доклады буенча фикер алышулар ачмаска. СССР Верховный Советы бу такдимне бер тавыштан кабул итә.

Аннары депутат **Багировның** такдиме буенча, СССР Верховный Советы, палаталарда аерым рәвештә тавышка куеп, бер тавыштан түбәндәге карарны кабул итә:

„Совет Социалистик Республикалар Союзы Верховный Советы хөкүмәтнең тышкы политикасы турында СССР Халык Комиссарлары Советы Председателе һәм Чит Ил Эшләре Халык Комиссары иптәш **Вячеслав Михайлович Молотов** докладын тыңлаганнан соң, карар бирә:

Хөкүмәтнең тышкы политикасын яхшы дип табарга“.

Шуның белән Союз Советының һәм Милләтләр Советының берләштерелгән беренче утырышы ябыла.

СОЮЗ СОВЕТЫНЫҢ ҺӘМ МИЛЛӘТЛӘР СОВЕТЫНЫҢ 31 нче МАРТТАГЫ БЕРЛӘШТЕРЕЛГӘН УТЫРЫШЫ

31 нче март 18 сәгаттә, Кремльдә, СССР Верховный Советының утырышлар залында Союз Советының һәм Милләтләр Советының берләштерелгән утырышы ачылды. Утырыш башланудан күп элек Кремльнең зур сараена депутатлар һәм кунаклар җыела башладылар. Ложаларда чит ил дипломатлары, Совет һәм чит ил матбугаты корреспондентлары.

Председатель өстәле артында Союз Советы Председателе депутат **А. А. Андреев,** Милләтләр Советы Председателе **Н. М. Шверник,** Союз Советы Председателе урынбасарлары депутат **Д. Т. Лысенко,** депутат **Усман Юсупов,** Милләтләр Советы Председателе урынбасарлары **Ч. А. Асланова,** депутат **М. В. Кулагин.** Ложаларда—СССР Верховный Советы Президиумы членнары һәм СССР хөкүмәте членнары. Аларның күренүләре көчле алкышлар белән каршы алына.

Утырышта: **Сталин, Молотов, Ворошилов, Каганович, Калинин, Жданов, Микоян, Хрущев, Маленков, Шкирятов, Булганин, Вышинский, Вознесенский, Землячка, Буденный, Бадаев, Багиров, Кузнецов, Тимошенко, Зверев, Первухин** иптәшләр һәм Верховный Совет Президиумының башка членнары һәм Халык Комиссарлары катнашалар.

Союз Советының һәм Милләтләр Советының берләштерелгән утырышын Милләтләр Советы Председателе депутат **Н. М. Шверник** ача. Сессия көн тәртибенең икенче мәсьәләсенә: Карелия Автономияле Совет Социалистик Республикасын Союзный Карель-Фин Совет Социалистик Республикасы итеп үзгәртеп кору мәсьәләсенә күчә.

Бу мәсьәлә буенча доклад өчен сүз депутат **А. А. Ждановка** бирелә. Аның трибунада күренүен депутатлар һәм кунаклар озакка сузылган көчле алкышлар белән каршы алалар.

Халык Комиссарлары Советының тапшыруы буенча депутат Жданов СССР Верховный Советы карамагына Карелия Автономияле Совет Социалистик Республикасын Союзный Карель-Фин Совет Социалистик Республикасы итеп үзгәртеп кору турындагы закон проектын кертә.

Карелия хезмәт ияләренең теләкләренә туры китереп, докладчы быел 12 нче мартта СССР белән Финляндия арасында төзелгән солых договоры буенча Советлар Союзына күчкән территорияләрне, Ленинградка якын ук булган кечкенә полосадан тыш, Карелия Автономияле Совет Социалистик Республикасына бирү мәсьәләсен куя. Бер үк вакытта Карелия Автономияле Совет Социалистик Республикасын Союзный Карель-Фин Совет Социалистик Республикасы итеп үзгәртеп кору турындагы мәсьәлә куела.

СССР Верховный Советы карамагына кертелә торган закон проектын укып чыкканнан соң, депутат Жданов сүз азагында, бөтен залның кул чабуы астында—Карелия Автономияле Совет Социалистик Республикасын Союзный Карель-Фин Совет Социалистик республикасы итеп үзгәртеп кору Ленин—Сталин милли политикасының яңа зур җиңүе булып тора ди һәм кардәш союз республикалар семьясе арасында яңа, 12 нче республиканың тууы күп милләтле дәүләтебезне ныгыту эшендә алга яңа адым ясау дигән сүз.

Фикер алышуларга катнашучы депутатлар—**П. Г. Соляков** һәм **М. В. Горбачев,** Карелия хезмәт ияләре исеменнән, Автономияле Карелия Совет Социалистик Республикасын Союзный Карель-Фин Совет Социалистик Республикасы итеп үзгәртеп кору турында СССР Халык Комиссарлары Советы тарафыннан СССР Верховный Советы карамагына кертелгән закон проектын раслауны сорап мөрәҗәгать итәләр.

Депутат **Б. А. Двинский** СССР Халык Комиссарлары Советы тарафыннан кертелгән закон проектын яклый һәм депутат Жданов доклады буенча фикер алышуларны туктатуны такдим итә.

СССР Верховный Советы, палаталарда аерым рәвештә тавышка куяю белән, Карелия Автономияле Совет Социалистик Республикасын Союзный Карель-Фин Совет Социалистик Республикасы итеп үзгәртеп кору, бу республикага аның территориясендә промышленностьны, гомуми союз әһәмияте булган кайбер предприятиеләрдән тыш, бирү турындагы законны бер тавыштан кабул итә. СССР Верховный Советы РСФСР Верховный Советыннан һәм Карель-Фин ССР Верховный Советыннан РСФСР белән Карель-Фин ССР арасындагы чикне ачык итеп билгеләү проектын СССР Верховный Советы карамагына кертүне сорарга карар бирде. СССР Верховный Советы Карель-Фин ССР дан СССР Верховный Советына депутатлар сайлауны үткәрергә карар бирде һәмСССР Верховный Советы Президиумына сайлаулар көнен билгеләргә кушты. СССР Верховный Советы шулай ук СССР Конституциясенең (Төп Законының) 13 нче статьясенә Совет Социалистик Республикалар Союзы составына Карель-Фин Совет Социалистик Республикасының керүе турында өстәмә кертергә карар бирде.

Законны кабул итү Советлар хөкүмәте хөрмәтенә, халыкларның бөек юлбашчысы иптәш Сталин хөрмәтенә көчле һәм озакка сузылган алкышлар астында барды.

СССР Верховный Советы тәнәфестән соң, көн тәртибендәге өченче мәсьәләне карауга күчте. Союз Советының һәм Милләтләр Советының берләшкән утырышында СССР ның 1940 нчы елгы дәүләт бюджеты проекты турындагы һәм СССР ның 1938 нче елгы дәүләт бюджетының үтәлеше турындагы доклад белән СССР финанс халык комиссары иптәш **А. Г. Зверев** чыкты.

Татарстан АССР радио тапшыруы работникларына

Татарстан АССР Совнаркомы һәм ВКП(б) ның Өлкә Комитеты үзләренең 15 еллыгын билгеләп үтүче радиотапшыруы работникларын тәбрик итәләр.

Радиотапшыруы үзенең 15 ел яшәү елларында бөтен илебездәге кебек орденлы Татарстан АССР да да хезмәт ияләре массасын коммунистик тәрбия итү һәм аларның культура дәрәҗәләрен һәр яклап күтәрү эшендә шактый уңышларга иреште.

Татарстан АССР Совнаркомы һәм ВКП(б) ның Өлкә Комитеты ТАССР радиотапшыруы работникларын, радиотапшыруның сыйфатын тагын да югарырак күтәрергә, Татарстанда радиотапшыруын ВКП(б) ның XVIII нче съезды һәм иптәш Сталин тарафыннан куелган бурычлар дәрәҗәсенә кую өчен булган мөмкинлекләрдән тулырак һәм кинрәк файдаланырга чакыралар.

ТАТАРСТАН АССР СОВНАРКОМЫ. ВКП(б) НЫҢ ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ.

* * *

Татарстан АССР Верховный Советының Президиумы Татарстан АССР радиотапшыруы работникларын совет радиотапшыруының 15 еллыгы уңае белән тәбрик итә.

Бөтен совет радиотапшыруы кебек, Татарстан АССР радиотапшыруының да хезмәт ияләре массасына коммунистик тәрбия бирү өлкәсендә 15 ел эчендәге уңышлары аз түгел һәм радиотапшыруы большевистик агитациянең куәтле коралы булып тора.

Татарстан АССР Верховный Советының Президиумы республикабызның радиотапшыруы работниклары орденлы Татарстан Автономия Совет Социалистик республиканың хезмәт ияләрен коммунистик тәрбия итүдә һәм культура дәрәҗәләрен күтәрүдә совет радиотапшыруын тагын да көчлерәк коралга әверелдерү өчен, киләчәктә тагын да яхшырак эшләячәкләренә ышаныч белдерә.

ТАТАРСТАН АССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ.

Язгы чәчу алдыннан

РЕЙД БАШЛАНДЫ

КАЙБЫЧ, 31 март. **(Телефон буенча).** 30 нчы мартта Кайбыч районындагы „Колхоз бригадасы“ һәм „Колхозная бригада“ газеталары редакцияләре киңәшмә үткәрделәр. Киңәшмәдә эшче-авыл хәбәрчеләре рейден оештыру турындагы мәсьәлә каралды. Барлык колхозларда һәм Мөрәле МТС ында рейд оештырылды.

Рейд бригадалары составында: район газетасы работниклары, хәбәрчеләр, партия, совет активлары, авыл хуҗалыгы белгечләре һәм җирле Совет депутатлары. Бригадалар бүген колхозларның һәм МТС ның язгы чәчүгә хәзерлеген тикшерүгә керештеләр.

Фирушин.

БӘРӘҢГЕНЕ ЯРОВОЙЛАШТЫРУГА КЕРЕШТЕЛӘР

МӨСЛИМ, 31 март. **(Телефон буенча).** Мөслим районы колхозлары бәрәңгене яровойлаштыруга керештеләр. Бәрәңге яровойлаштыру өчен „Туры юл“ һәм „Кызыл Октябрь“ колхозлары 48 әр центнер, „Путиловец“ һәм „Кызыл көч“ колхозлары 30 ар центнер бәрәңге салдылар.

ТРАКТОРЛАР ЭШ УРЫННАРЫНА ЧЫКТЫЛАР

ТЫМЫТЫК, 31 март. **(Телефон буенча).** Тымытык МТС ының барлык трактор бригадалары эш урыннарына киттеләр. Бригадалар качок, су һәм май чиләкләре кебек ярдәмче инвентарьларбелән тулысынча тәэмин ителделәр. Бригадалар прицепщиклар, ягулык һәм су ташучылар белән комплектовать ителделәр.

Иптәш Галимов һәм тракторчы хатын-кызлар бригадалары кыр эшләрен аеруча оешканлык белән каршылыйлар.

Зәйнуллин.

МТС ның өлкән механигы.

СССР ның тышкы политикасы турында иптәш В. М. Молотовның СССР Верховный Советының VI нчы Сессиясендә ясаган доклады турында чит ил матбугаты

ГЕРМАНИЯ

БЕРЛИН, 30 март. (ТАСС). Германия информация бюросының хәбәр итүенә караганда, Германия матбугаты иптәш Молотов докладының тулы аңлатмасын урнаштыра. „Берлинер берзенцейтунг“ газетасы „Молотов доклады сугыш уты кабызучыларга отпор бирде“ дип яза. Газета болай ди:

„СССР Чит Ил Эшләре Халык Комиссарының доклады СССР ның ныклы һәм бәйсез политика үткәрүен күрсәтә. СССР га үз юлы белән барырга бер кем дә комачаулый алмас. Шуның белән бергә, доклад СССР ның Якын Көнчыгышта көнбатыш державаларының интригалары турында бик яхшы белеп торуын һәм үзенең нейтралитетына кагылырга, үзенең чикләрендә тынычлыкны һәм куркынычсызлыкны бозарга ирек бирмәячәген күрсәтә“.

Аннары газета иптәш Молотовның Совет-Германия арасындагы дуслык мөнәсәбәтләре турында белдерүен аеруча күрсәтеп үтә.

„Фелькишер беобахтер“ газетасы СССР Верховный Советы Сессиясенең ачылуы турында тулы хәбәр һәм иптәш Молотовның докладын урнаштыра. Доклад турындагы хәбәрне газета „Совет-Германия дуслыгының уңышлы үсеше“ дигән баш астында бирә.

„Дейче альгемейне цейтунг“ газетасы да Верховный Совет Сессиясе ачылу турында тулы итеп яза, партия һәм хөкүмәт юлбашчыларының залга килеп керүләрен депутатларның көчле алкышлар белән каршы алганлыкларын күрсәтеп үтә. Иптәш Молотов доклады турындагы хәбәрне газета: „Молотов доклады СССР Верховный Советы депутатлары тарафыннан бердәмлек белән яхшы дип табылды“ дигән сүзләр белән тәмамлый.

„Цвельфурблат“ газетасы һәм башка газеталар да иптәш Молотов доклады турында тулы белдерүләр урнаштыралар.

БЕЛЬГИЯ

БРЮССЕЛЬ, 30 март. (ТАСС). Бельгия матбугаты СССР Верховный Советы Сессиясендә иптәш Молотов ясаган докладка киң урын бирә. „Вентьем сьекль“ һәм „Суар“ газеталары СССР тынычлык һәм нейтралитет политикасын үткәрә дип язалар. Барлык газеталар иптәш Молотов докладының империалистик державаларның СССР га һөҗүм итү өчен Финляндияне плацдарм итеп файдаланырга уйлаганлыклары турындагы урынны аеруча күрсәтеп бирәләр. „Пепль“ һәм „Либр бельжик“ газеталары иптәш Молотов докладына күрнекле урын бирәләр. „Эндепанданс бельж“ газетасы иптәш Молотов докладын урнаштырып, СССР бөтен Финляндияне ала алган булыр иде, ләкин үзенә куркынычсызлыкны тәэмин итү өчен кирәк булган минимум таләпләр белән канәгатләнеп, ул кадәргә бармады дип яза.

НОРВЕГИЯ

ОСЛО, 30 март. (ТАСС). Барлык Норвегия газеталары иптәш Молотов докладының аңлатмасын басып чыгаралар. „Афтенпостен“ газетасы иптәш Молотов доклады турындагы белдерүне урнаштырып, Финляндиядәге сугыш Кызыл Армиянең гүзәл җиңүе булганлыкны күрсәтеп үтә. „Моргенпостен“ һәм „Тиденс-тейн“ газеталары төп игтибарны төньяк илләрнең оборона союзы дип аталган союз турындагы мәсьәлә буенча СССР ның позициясенә юнәлдерәләр.

ШВЕЦИЯ

СТОКҺОЛЬМ, 30 март. (ТАСС). Швециянең барлык газеталары иң күренерлек урында иптәш Молотов докладының аңлатмасын иглан иттеләр. „Дагенс нюхетер“ газетасы Сессиянең эше турындагы хәбәрләргә бер бит диярлек урын биргән. Газеталар иптәш Молотов портретын урнаштырдылар. Күп кенә газеталар оборона союзы дип аталган нәрсәне төзү планнарына зур игтибар биреп, иптәш Молотовның мондый союз төзү СССР ның Финляндия белән төзелгән бөтен солых договорына каршы килер иде, Финляндиянең СССР га каршы сугыш ягыннан нинди булса да үч алу союзында катнашуы бу договорга турылыклы булу белән бергә була алмый, ә Швециянең һәм Норвегиянең мондый союзда катнашулары бу илләрнең үзләренең нейтралитет политикаларыннан баш тартулары дигән сүз булыр иде дип белдерүен аеруча күрсәтеп үтәләр.

БОЛГАРИЯ

СОФИЯ, 30 март. (ТАСС). Совет хөкүмәтенең тышкы политикасы турында иптәш Молотовның доклады Болгария матбугатының игтибар үзәгендә тора. Иртәнге газеталарның беренче битләрендә иптәш Молотов докладының тулы аңлатмасы бирелгән, Верховный Советның моннан элекке Сессияләре утырышларының күп санлы рәсемнәре һәм иптәш Молотов портретлары урнаштырылган. Газеталар иптәш Молотовның докладын: „СССР халыклар тынычлыгын һәм нейтралитетны саклаячак“, „Молотов СССР ның тынычлык һәм нейтралитет политикасын раслады“, „СССР га каршы һөҗүм итәргә маташуларның җимерелүе“, „Совет политикасы сугышны чикләүгә юнәлдерелгән“ кебек зур башлар астында басалар. Докладтан „Советлар Союзы бер кайчан да чит политика коралы булмады һәм булмас, башка илләрдәге әфәнделәргә ошау яки ошамау белән хисаплашмастан үз политикасын үткәреп килде һәм үткәрер“ дигән урынны газеталар аеруча күрсәтеп үтәләр. Газеталар иптәш Молотов докладының Финляндия мәсьәләсенә һәм Кызыл Армиянең Советлар Союзына дошман булган күп кенә империалистик илләрнең берләшкән көчләрен җиңүенә багышланган бүлеген киң төстә яктырталар. Газеталар фин сугыш чукмарларының яраланган һәм плен төшкән кызыл армеецләрне ерткычларча җәзалауларын әйткән урыннарны китерәләр. Газеталар соңгы вакытларда төрле авторлар тарафыннан куела торган һәр төрле үч алу планнарының, төньяк илләрнең оборона союзы дип аталган планның өметсезлеген аеруча күрсәтәләр.

Иптәш Молотовның СССР ның көньяктагы күршеләре белән мөнәсәбәтләре турындагы белдерүенә газеталар аеруча игтибар бирәләр.

Бөтен Болгария җәмагатчелеге иптәш Молотовның докладын гаят зур кызыксыну һәм игтибар белән каршылады.

ЛИТВА

КАУНАС, 30 март. (ТАСС). Бөтен Литва матбугаты күренекле урында СССР Верховный Советының VI нчы Сессиясенең эше турындагы белдерүне урнаштыра. Газеталар: „Кичә Молотов әһәмиятле речь сөйләде“, „Молотов речендә бик күп әһәмиятле һәм зур мәсьәләләр куелды“ дигән баш астында иптәш Молотов докладының тулы аңлатмасын урнаштыралар. Литва җәмагатчелеге иптәш Молотов доклады белән гаят дәрәҗәдә кызыксына.

ЛАТВИЯ

РИГА, 30 март. (ТАСС). Иптәш Молотовның СССР Верховный Советының VI нчы Сессиясендә ясаган доклады Латвиядә тирән канәгатләнү белән каршы алынды. Латвия җәмагатчелеге иптәш Молотовның Советлар Союзының Балтык буе дәүләтләре белән үзара мөнәсәбәтләре турындагы белдерүен аеруча канәгатләнеп каршы алды.

„Ритс“ газетасы иптәш Молотов докладында Советлар иленең тынычлык политикасының һәм нейтралитетының эзлеклелеге турында, шулай ук СССР ның үзенең интересларын бозуга юл куймаячагы турында әйтелгән урынны аеруча күрсәтеп үтә.

„Латвияс карейвис“ газетасы иптәш Молотов докладының тулы аңлатмасын урнаштырып, Кызыл Армиянең Финляндиядә дошманнарның берләшкән көчләренә каршы көрәшкәнлеген аеруча күрсәтеп үтә.

„Яунакас зиняс“ газетасы да иптәш Молотов докладының тулы аңлатмасын урнаштыра. Газета болай дип яза:

„СССР киләчәктә дә үзенең нейтралитетын бөтен кискенлек белән саклар. Империалистлар Советлар Союзының бер кайчан да чит политика коралы булмаячагын аңларга тиешләр“.

„Брива земе“ газетасы иптәш Молотов докладын урнаштырып, Балтык буе дәүләтләренә кагыла торган урыннарын аеруча күрсәтеп үтә. Докладның бу өлешен газета: „Балтык диңгезе ярларының куркынычсызлыгы нығытылды“ дигән баш астында бирә.

ИТАЛИЯ

РИМ, 30 март. (ТАСС). Италиянең барлык газеталары иптәш Молотов доклады турында тулы белдерү иглан иттеләр.

ЭСТОНИЯ

ТАЛЛИН, 30 март. (ТАСС). Эстониянең барлык газеталары СССР Верховный Советының VI нчы Сессиясендә иптәш В. М. Молотов ясаган докладны басып чыгаралар. „Уус эсти“ газетасы докладка түбәндәгечә баш биргән: „Молотов Москвада үзенең зур тышкы политик речендә СССР белән Балтык дәүләтләре арасындагы мөнәсәбәтләр үсешенең әчке һәм тышкы политика мәсьәләләрендә уңайлы нәтиҗәләр биргәнлеген белдерде“. „Постимесс“ газетасы болай дип яза:

„Тынычлык, нейтралитет һәм дәүләтнең оборона сәләтен ныгыту,— Советлар Союзының тышкы политикасында Молотов рече белән куелган бурычлар әнә шулар“.

Шул ук вакытта газета СССР Верховный Советының VI нчы Сессиясенең ачылуы турындагы отчетны урнаштыра.

ДАНИЯ

КОПЕНҺАГЕН, 30 март. (ТАСС). Дания матбугаты СССР Верховный Советының VI нчы Сессиясенең эше турында тулы белдерү урнаштыра. „Политикен“ газетасы иптәш Молотов докладының тулы аңлатмасын урнаштырып, төньяк дәүләтләренең оборона союзы дип аталган нәрсә турындагы мәсьәлә буенча Советлар Союзының позициясен аеруча күрсәтеп үтә. Газета иптәш Молотовның портретын урнаштыра.

АКШ

НЬЮ-ЙОРК, 30 март. (ТАСС). „Нью-Йорк таймс“ һәм „Нью-Йорк геральд трибюн“ газеталары иптәш Молотов доклады турындагы белдерүне зур башлар белән һәм күрнерлек урында басып чыгардылар. Газеталар докладны тулысынча аңлатып, аерым алганда иптәш Молотовның СССР ның һәм АКШ ның мөнәсәбәтләре турындагы сүзләрен китерделәр.

ЯПОНИЯ ХӨКҮМӘТЕНЕҢ ДЕКЛАРАЦИЯСЕ

ТОКИО, 30 март. (ТАСС). Домей Цусин агентлыгы Кытайда Ван Цзин-вей житәкчелегендә „яңа үзәк хөкүмәт“ төзелү уңае белән радио буенча Япония хөкүмәтенең декларациясен тапшыра. Декларациядә Японияның киләчәктә „Көнчыгыш Азиядә яңа тәртип урнаштыру“ политикасын үткәрәчәге, Ван Цзин-вей „хөкүмәтенә“ ярдәм күрсәтәчәге белдерелә. Аннары декларациядә Кытайда өченче державаларның интересларына тиешенчә хөрмәт ителәчәге әйтелгән. Ахырдан декларациядә „Кытайда японияга каршы көчләргә каршы хәрби операцияләр дәвам иттереләчәк“ диелә.

ШАНХАЙНЫҢ КЫТАЙ ХАЛКЫ ВАН ЦЗИН-ВЕЙГӘ КАРШЫ

ШАНХАЙ 30 март. (ТАСС). Нанкинда ванцзинвейчылар хөкүмәте оештырылуга каршы протест йөзеннән, бүген урта һәм югары мәктәпләрнең укучылары һәм укытучылары забастовка иглан иттеләр. „Цзунмейжибао“ газетасының хәбәр итүенә караганда, педагоглар һәм укучылар ассоциациясе өндәмә чыгарган. Бу өндәмәдә болай диелә: „Хиянәтче Ван Цзин-вейнең битлеге ачылды. Ван Цзин-вейнең оста яшренгән һәм оятсыз хиянәтче икәнлеге хәзерге вакытта һәрбер кытайга ачык. Без японнарга һәм аларның курчагы булган Ван Цзин-вейнең заговорына каршы тору өчен бөтен көчебезне куячакбыз. Безнең хәрәкәткә Кытайның барлык гражданнары кушылырлар дип ышанабыз.

Шанхайның төрле җәмагат оешмалары исеменнән чыгарылган икенче бер өндәмәдә болай диелә: „Без—Ван Цзин-вейгә каршы көрәшче ...

ВАН ЦЗИН-ВЕЙ „ХӨКҮМӘТЕНЕҢ“ ТӨЗЕЛҮЕ

ШАНХАЙ, 30 март. (ТАСС). Бүген иртә белән Нанкинда япон властьлары җитәкчелегендә төзелгән һәм Кытайның Ван Цзин-вей җитәкчелегендәге „үзәк хөкүмәте“ дип аталган хөкүмәтнең төзелүе иглан ителде. „Хөкүмәт“ 11 министрдән һәм 3 комиссиядән тора.

КЫТАЙ РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ЧИТ ИЛ ЭШЛӘРЕ МИНИСТРЛЕГЕНЕҢ НОТАСЫ

ЧУНЦИН, 30 март. (ТАСС). Юнайтед Пресс агентлыгы радио буенча Кытай республикасының чит ил эшләре министрлегенең чит илләрнең Кытайдагы илчелекләренә һәм миссияләренә, шулай ук Кытай илчеләре аркылы тиешле хөкүмәтләргә тапшырылган нотасын тапшыра. Нотада болай диелә:

„Кытайга басып кергән моменттан бирле Япония үзенең Азияне һәм Тын океанны басып алу һәм анда үзенең хакимлеген урнаштыру теләген тормышка ашыру өчен бөтен средстволардан файдаланды. Үтерүләр, көчләүләр, талаулар, тыныч халыкны һавадан бомбага тотулар һәм башка төрле варварлык актлары тыныч халыкка чиксез зыян һәм җәфалар китерделәр, ләкин болар берсе дә японнар теләгән нәтиҗәләргә китермәделәр, бәлки Кытайның каршылык күрсәтүгә омтылышын көчәйттеләр генә. Кытай үз алдына гаделлекне яклау теләгән генә куя.

Кытайның 3 ел чамасы каршылык күрсәтүе нәтиҗәсендә япон милитаристлары, бу каршылыкны сындырудан өметләрен өзеп, Нанкинда аларның уенча „Кытай республикасының милли хөкүмәте“ булырга тиеш булган оешма төзергә карар бирделәр. Ләкин бу „хөкүмәт“ япон милитаристлары тарафыннан контрольлек ителә торган һәм алар тарафыннан Кытайның суверенный хокукларын бетерү, аның бәйсезлеген, административ һәм территориаль бөтенлеген юк итү өчен төзелгән курчак оешмадан башка нәрсә түгел. Японнар бу оешманы шулай ук халыкара хокукны һәм тәртипне җимерү, 9 держава договорын юкка чыгару, Кытайда өченче державаларның бөтен сәүдәсен һәм интересларын бетерү өчен дә файдаланылачаклар.

Курчак оешма составына кергән кешеләрнең япон лакейларының бер төркеме генә икәнлеге, мораль яктан таркалган һәм һәр төрле әдәп һәм патриотизм хисләрен югалткан кешеләр икәнлеген әйтеп торасы да юк. Японнар агрессиясенә ярдәм күрсәтеп һәм аны көчәйтеп, алар үз язмышларын куркынычка дучар иттеләр, чөнки Кытай хөкүмәте һәм халкы аларны законга туры китереп иң нык җәзаланырга тиеш булган иң начар типтагы хиянәтчеләр дип хөкем иттеләр.

Әле яңа гына Нанкинда төзелгән законсыз оешма тарафыннан һәм Кытайда кайда булса да яшәве ихтимал булган нинди булса да башка курчак оешма тарафыннан эшләнгән һәрбер актның нинди булса да көчтән мәхрум ителгәнлеге һәм Кытайның хөкүмәте һәм кытай халкы тарафыннан бер кайчан да танылмаячагы турында күп кенә хәлләрдә инде иглан ителгән декларацияне тагын да ныклырак формада кабатлау өчен Кытай хөкүмәте шушы мөмкинлектән файдаланырга тели. Кытай хөкүмәте, үзләрен ихтирам итүче барлык дәүләтләрнең халыкара мөнәсәбәтләрдә законны һәм гаделлелекне кулланып эш итәчәкләренә һәм Японияның Кытайдагы курчак оешмасын бер кайчан да де-юре яки де-факто танымаячакларына ышана. Мондый һәр бер тану, ул нинди генә формада булса да, халыкара хокукны бозу булыр иде һәм кытай милләтенә карата дусларча булмаган акт дип каралыр иде. Моның нәтиҗәсе өчен танучы як бөтен җаваплылыкны үз өстенә алырга тиеш.

Япония ни генә эшләргә маташса да, басып алучылар Кытай территориясеннән тулысынча куылганга кадәр һәм хокук көчне җингәнгә кадәр Кытай хөкүмәте һәм халкы үзләренең каршылык күрсәтүен дәвам иттерергә һәр вакыттагы кебек үк хәзер торалар“.

КОЛХОЗЛАРДА БАЛЫК ҮРЧЕТҮ

Татарстан колхозларында балык үрчетү чаралары үткәрелә. 500 гектар күләмендәге күлләргә һәм буаларга быел 200 мең данә карп балыгы җибәреләчәк. Тере балыклар белән колхозларны тәэмин итү Татарстан балык трестына йөкләнде.

Әгерҗе районының Фрунзе исемендәге колхозында, Арча районының „Мәгариф“, Тымытык районының „Мелиорация“ колхозларында балык питомниклары хәзерләнә. Кайбыч, Норлат, Беренче Май районнары колхозларында һәм башка районнардагы колхозларда 200 гектар мәйданда балык питомниклары төзеләчәк.

Кызамыкка каршы көрәш

Татарстан Сәламәтлек Саклау Халык Комиссариаты кызамык авыруына каршы көрәшне көчәйтү буенча күп кенә чаралар үткәрә. Апрель-май айларында Чистайда, Бөгелмәдә һәм Алабугада врачларның районара конференцияләре үткәреләчәк. Конференцияләргә Казаннан профессорлар һәм квалификацияле врачлар баралар. Алар районнарда эшләүче врачларны кызамыкка каршы көрәшнең яңа методлары белән таныштырачаклар.

Балаларны кызамык авыруыннан саклау өчен соңгы елларда махсус сыворотка кулланыла. Шуның аркасында балаларның кызамык белән авырулары шактый кимеде. Казанда кызамыкка каршы көрәш станциясе шушы елның беренче кварталында район больницаларына 20 литр сыворотка җибәрде. Бу сыворотка 1939 нчы елда бөтен ел буена 30 литр җибәрелгән иде. Яслеләрдә, балалар бакчаларында һәм больницаларда балаларның тәненә сыворотка җибәрүгә өйрәтү өчен махсус курслар аркылы сестралар хәзерләнә.

ЕЛГАЛАРДА

Соңгы көннәрдә Волга, Кама, Ока буйларында җеншек кар һәм яңгырлар яуды. Шуның аркасында елгаларда су тизлек белән арта башлады. 31 нче мартка каршы бер тәүлек эчендә Оканың югарыгы агымында 68—187 сантиметр су артты. Орел янында боз ага башлады. Калуга янында боз кузгалды.

Волга суы соңгы бер тәүлек эчендә Вязовые янында 14 сантиметр, Югары Ослан янында 11 сантиметр, Кама Тамагы янында 8 сантиметр артты. Ташу башланганнан бирле Югары Ослан янында арткан су 83 сантиметрга житте.

Кама суы соңгы бер тәүлек эчендә Красный Бордан алып Лаешка кадәр 4—14 сантиметр артты. Зөя суы бер тәүлек эчендә Борындык янында 184 сантиметр, Казанка суы Арча янында 114 сантиметр, Зәй суы Заинский янында 151 сантиметр, Чишмә суы Петропавловка янында 110 сантиметр артты.

Редактор урынбасары И. ҮЗБЕКОВ.
Зам. редактора И. УЗБЕКОВ.

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
1 һәм 2 нче апрельдә премьера
ТАНЯ
Талоннар белән кертелми.
Спектакль кич 7 сәгат 30 минутта башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
1, 2, 3 һәм 4 нче апрельдә
В. Шкваркин әсәре премьера
КУРКЫНЫЧЛЫ СУД
Талоннар белән кертелми.
Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 7 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ
Татар Дәүләт Академия театры бинасында
3 нче апрельдә
ФАЙДАСЫЗГА САКЛАНУ
4 нче апрельдә
ИРЕК
Талоннар белән кертелми.
Коллектив рәвештә килү өчен 29—84 телефоны буенча заявкалар алына.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген цирк эшләми. Иртәгә
ЗУР ЦИРК УЕНЫ
ФРАНЦУЗЧА КӨРӘШ
ЯРЫШЫ
ҺӘР КӨН 3 ПАР КӨРӘШӘ
Уен көндез 12 дә, кич 8 дә башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 11 гә кадәр ачык.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 10, 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тавышлы, художествоолы яңа фильм ЗУР ТОРМЫШ
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8, һәм 10 да.	ШАТЛЫК ЭЗЛӘГӘНДӘ
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 2, 4, 6, 8, 10 да.	ВОЛГА-ВОЛГА
„ЧАТКЫ“ 6, 8, 9-30 да.	ШӘХСИ ЭШ
„ПИОНЕР“ 10, 11-30, 1, 2, 3-30, 5, 6-30, 8-20.	ШӘХСИ ЭШ Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тавышсыз фильм Дипкурьер сумкасы
„РОТ-ФРОНТ“ 6, 8, 10 да.	КЕЧКЕНӘ АНА
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	ТАШЛАНДЫК

Фото-Желатин заводы төзелешенә, монтаж һәм эксплоатация буенча эшләү өчен 6—7 нче РАЗРЯД ЭЛЕКТРОМОНТЕРЛАР КИРӘК. Тору урны бирелә. Казан, Восстание бистәсе, Фото-Желатин заводының кадрлар булеге. 474—5—5

ТАТАРСТАН ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ СОВЕТ ХӨКҮМӘТЕНЕҢ ТЫШКЫ ПОЛИТИКАСЫН БЕРДӘМ РӘВЕШТӘ ЯХШЫ ДИП ТАБАЛАР

Без үз участкыларыбызда стахановча эшләрбез

СССР Верховный Советының VI нчы Сессиясе ачылу уңае белән Тымытык районының Вахитов исемендәге совхозында эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең митингысы булды. Митингта 473 кеше катнашты. „СССР хөкүмәтенең тышкы политикасы турында“ Совет хөкүмәте башлыгы иптәш Молотовның докладын радио буенча тыңлаганнан соң, митингта катнашучылар зур канәгатләнү белдерделәр һәм СССРның Сталинчыл политикасын тулысы белән яхшы дип таптылар.

Иптәш Осокин үзенең чыгышында болай диде:

— Сугыш провокаторларының һәм сугыш уты кабызучыларның маскасын ачып, Советлар Союзы Сталинчыл тынычлык политикасы принципларына турылыклы булган хәлдә, үзенең тышкы политикасында яңа уңышларга иреште. Данлыклы Кызыл Армиябезнең көче һәм куәте белән безнең төньяк-көнбатыш чикләребезнең һәм Ленин шәһәренең куркынычсызлыгы тәэмин ителде.

Митингта катнашучы иптәш Зәйнуллин болай диде:

— Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының бөек патриотлык омтылышы белән рухланган сугышчылары, командирлары һәм политработниклары большевиклар ала алмаслык крепостьның юк икәнлеген күрсәттеләр. Англия-Франция империалистларының бөтен Европада сугыш уты кабызу планнары җимерелде.

Иптәш Капля, илебез тагы да куәтлерәк һәм ныграк булып әверелде, без һәрберебез үз участкыбызда стахановча эшләргә тиешбез, диде.

Митингның бер тавыштан кабул ителгән резолюциясендә болай диелә:

—Англия - Франциянең реакцион буржуазиясе тарафыннан кабызылган икенче империалистик сугышка каршы СССР ның тынычлык өчен көрәш политикасын тулысынча яхшы дип табабыз һәм котлыйбыз. Без үз участкыларыбызда стахановча эшләргә тиешбез.

Татарстан хезмәт ияләре СССР Верховный Советының VI нчы Сессиясе материалларын өйрәнәләр. РӘСЕМДӘ: жиркомбинатның сабын цехы эшчеләре Сессиядә хөкүмәтнең тышкы политикасы турында иптәш Молотов ясаган доклад турында митингта С. Латыйпов иптәшнең информациясен тыңлыйлар.
И. Галиев фотосы.

Яшәсен җиңелмәс Кызыл Армия!

Апас районы Дәүләки колхозы членнары һәм агитаторлары иптәш Молотовның СССР Верховный Советының VI нчы Сессиясендә ясаган докладын радио аркылы тапшыруны зур игтибар һәм канәгатләнү белән тыңладылар.

Докладны тыңлаганнан соң зур митинг булды. Митингта партиянең башлангыч оешмасы секретаре иптәш Хәсәнев чыгыш ясады. Ул болай диде:

— Совет дәүләте тарафыннан тайпылышсыз үткәрелә торган Сталинчыл тышкы политика яңа гүзәл җиңүгә иреште. Социализм иленең куркусыз сугышчылары үзләре өчен үтә алмаслык киртәләрнең булмавын тагын бер тапкыр күрсәттеләр.

Митинг иптәш Молотов докладын кайнар рәвештә яхшы дип тапты һәм резолюция кабул итте. Колхозчылар язгы чәчүне кыска срокларда югары сыйфатлы итеп үтәргә йөкләмә алдылар.

ӘЛКИДӘ МИТИНГ

СССР Верховный Советының VI нчы Сессиясе ачылуга багышлап, Әлки районының Культура йортында күп кеше катнашы белән митинг булды. Колхозчылар, колхозчы хатын-кызлар, район үзәгенең эшчеләре һәм хезмәткәрләре иптәш Молотов докладын зур игтибар белән тыңладылар.

Митингта чыгып сөйләүчеләр Совет хөкүмәтенең Сталинчыл политикасын кайнар рәвештә котладылар. ВЛКСМ райкомы секретаре иптәш Михайлов үзенең чыгышында болай диде:

— Безнең бурыч—социализм иленең куәтен тагын да ныгыту, төньяк-көнбатыш чикләребезнең һәм Ленин шәһәренең куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен данлыклы Кызыл Армиябезнең сугышчылары көрәшкән кебек эшләүдән гыйбарәт.